ФӘРИТ
СУФИЯРОВ

# ГОМЕР ЯЗЛАРЫ



ФӘРИТ
СУФИЯРОВ

# ГОМЕР ЯЗЛАРЫ

КИТАП

УФА • 2002

УДК 894. 343-3
ББК 84 (2 Рус-Тат)
С 88

**Суфияров Ф. С.**

С 88 Гомер язлары: Шигырьләр, поэмалар, җырлар. — Уфа, Башкортстан «Китап» нәшрияты, 2002. — 176 бит.

ISBN 5-295-03058-X

Авторның яңа җыентыгына соңгы елларда язылган, заман вакыйгаларына аваздаш әсәрләре тупланган. Аларда шагыйрьнең югары әхлакый эзләнүләре, тетрәндергеч күңел хисләре чагылыш таба.

УДК 894.343-3
ФП — 2001 ББК 84 (2 Рус-Тат)
ISBN 5-295-03058-X © Суфияров Ф. С., 2002

# БОЛЫН ЧӘЧӘКЛӘРЕ

Малай кеше булсам да, бәләкәй чакта мин болын чәчәкләрен ярата идем. Бу — матурлыкка табан тәүге тапкыр омтылуым булгандыр. Кар сулары да кибеп бетмәстән үк авылдан ерак түгел болында пәйда булган йомры таҗлы сары чәчәкләрне җыеп кайтканым әле дә хәтердә. Җәй башларында инде чәчәкләрнең бихисап күптөрле, күптөсләре әрәмә болыннарын каплап ала... Малайлар сабантуе оештырып, бүләккә әнә шул чәчәкләрдән гөлләмәләр әзерләгәнебез дә хәтердә. Гомумән, авыл баласының нәни чагындагы хатирәләренең иң гүзәл бизәге — әнә шул болын чәчәкләреДер ул. Шагыйрь якташым Фәрит Суфияровның «кочагыма алып чәчәкләрне, болын буйларыннан урадым» дигән юлларын укыгач та шулар искә төште. Ә инде сезнең кулыгыздагы шушы җыентыкны, ягъни шагыйрь иҗатының ару ук зур шигъри гөлләмәсен тансыклап карап чыккач, аның шигырьләрен болын чәчәкләре белән тиңлисем килде. Әйе, бакчаныкы белән түгел, нәкъ менә болын чәчәкләре белән. Болын чәчәкләрен бит беркем дә чәчеп-карап үстерми, аларга су сипми, ыжгыр җилләрдән сакламый: алар табигый, керфек-таҗларын ачып, дөнья ничек булса, аңа шулай багалар...

Фәрит Суфияровның шигърияте дә иң беренче чиратта нәкъ әнә шул табигыйлеге белән алдыра. Дөнья ничек бар, шагыйрь аны шулай кабул итә. Шуңа күрә сез монда ясалма, төче, ялган бизәкле, аллы-гөлле шигырьләр күрмәссез. Бу үзенчәлекле шагыйрьнең шигъриятен болын чәчәкләренә тиңләвем — аның шигырьләренең тышкы буяуларын түгел, эчке халәтен аңлатырга тырышуым гына. Әйе, Фәрит Суфияровның шигъри әсәрләре табигатьнең үзе кебек үк кырыс та, мәрхәмәтле дә. Әйткәндәй, аның байтак шигырьләренең җирлеге, үзәге — табигать күренешләре, табигать тудырган хикмәтләр. Әмма шагыйрьнең максаты — һәркемгә дә таныш күренешләрне шигъри юлга салып тасвирлау гына түгел: йә бу күренешләр — аның тойгыларын, рухи халәтен, булмышын ачыклаучы чара, йә әдип теге яки бу табигать күренешен тасвирлап, үзенчә, башкалар әйтмәгән фикер бәян итә.

«Сулар ага, гомер уза,
Йөрәгем ник сулкылдый?
Тирбәлә дә җаным тына,
Ярга каккан дулкындай».

«Каеннарым яшел шәлен болгап
Торып кала офык артында.
Минем хәлне алар аңлый төсле,
Җырлар көйли сөю хакында».

яки менә тагын бер шигырьдән өзек:

«Пешкән икмәк кебек аңкый исе,
Челләләрдә ашлык өлгерә.
Үсмер чагы әле арышларның —
Шук малайлар кебек йөгерә».

Гап-гади, күз алдында яткан күренешләр хакында болай итеп беркемнең дә тасвирлаганы юк иде әле. Әйткәнемчә, чәчәкләр җирдән — сут, кояштан нур алган кебек, шагыйрь Фәрит Суфияров шигъриятенең чыганагы — табигать.

Үзе дә олы тормыш мәктәбе үткән Фәрит Суфияровның лирик геройлары — җир эшен, игенче һөнәрен үз иткән табигать балалары, хезмәт, намус, гаделлек төшенчәләре, яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи уйланулар, яшәү яме һәм күңел матурлыгына мәдхия — Фәрит Суфияров иҗатының асылын билгели. Болын чәчәкләре кебек табигый рухта, көчәнмичә, гади укучы күңеленә хуш килерлек итеп язылган алар. Һәрхәлдә, мин аларны шулай кабул иттем. Сез дә, кадерле укучылар, шундый ук хисләр кичерерсез дип уйлыйм. Әмма, чәчәкләрнең матурлыгын күрү өчен, болынга барырга кирәк, аларны аңлау өчен шагыйрь күзләре, шагыйрьнең күңел күзләре белән багарга кирәк. Ә серле шигърият болыны исә — сезнең алда...

*Рәдиф ТИМЕРШИН,*
*шагыйрь,*
*Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре,*
*Г. Чокырый исемендәге премия лауреаты*



# Шигырьләр

## ЗАМАНДАШ

Егерменче гасыр кешесемен,
Туры килде гомер бу чорга.
Йолдызларга, айга замандашым
Галәм корабларын очыра.

Хыялларны чынга ашырасың,
Бәхет ача безгә ишеген.
Сокландыра кеше язмышлары,
Яшәү мәгънәсенә төшендем.

Офыклар киң иҗат, хезмәтеңә,
Куанычка кеше зарланмас.
Игенчесе, эшче, инженеры —
Барысы да минем замандаш.

Яшәү ямен өсти бүгенге көн,
Шикләнмимен һич тә аз гына.
Биек үрләр яулап, юллар сала
Замандашым тормыш язына.

Йолдызларга салган юлларының
Маршрутын мин дә ачыклыйм.
Зәңгәр ташын айның алып төштең,
Замандашым, сиңа гашыйкмын.

## ИГЕНЧЕ

Кызган табага баскан күк,
Сикергәли, ашыга.
Бөтен авыл халкы бердәм
Иртән чыга басуга.

Кары-бозы бетми кала,
Язгы чәчү мәленә.
Табигать кырыс, керми шул
Игенченең хәленә.

Авыл кешесе хәстәрле,
Йөкләп ала өстенә.
Уттан чыга, суга керә
Урак, печән өстендә.

Татлы йокыларын бүлә,
Сусаганда су тапмый.
Игенче бер максат белән
Басу юлыннан атлый.

Тынгысыз җаннар икәнен
Гомер буе исбатлый.
Теләге, нияте изге, —
Тап төшермичә саклый.

Шөгыленә гашыйк булгач,
Ихтыяр көче җиңә,
Игенче язмышы белән
Бәйләнгән Туган җиргә.

## ҖИРЕМ ЮМАРТ

Җирем, күгем, дәрьяларым,
Сезгә ихлас эндәшәм.
Юксынып торам йокымнан,
Бик аз гына күрмәсәм.

Кодрәтлесең, зәңгәр күгем,
Нурларыңа күмәсең.
Анам кебек игътибарлы,
Назларыңа төрәсең.

Җирем, яшел бишегем син, —
Иң тәүдә аяк бастым;
Рәхмәтлемен бары сиңа —
Тормыш ишеген ачтым.

Урап ага дәрья сулар,
Ярлары тулы, сыймый.
Көмеш чулпылар шикелле,
Колак төбендә чыңлый.

Татлы суларын эчәмен,
Сафланам һавасына.
Җир күрсәтә юмартлыгын
Бар адәм баласына.

## ХАЛКЫМ

Илдә улап ач бүреләр,
Тол хатыннар елады.
Халкым онытмас мәңгегә
Ул каһәрле елларны.

Күзләрендә канлы яше,
Күңелендә ах-зары —
Көн итсә дә тирен түгеп,
Мохтаҗлык күрә ярлы.

Кол хәлендә яшәгәчтен
Тормыш яме калмады.
Төрле чиндагы түрәләр,
Халкым, сине алдады.

Афәтле, хәвефле хәлләр
Гомерләр агышында.
Кемнәр соң гамьсез карады
Халкымның язмышына?

Яман шеш кебек сызлата —
Яралар төзәлмәгән.
Тик ышаныч югалмаган,
Өметләр өзелмәгән.

Ерак чорлар аша үттең
Кыйбла ягына табан.
Көрәш мәйданында, халкым,
Ирек яулыйсың һаман.

## ҖЫР КИРӘК

Игенчеләр иген үстерәләр,
Төзүчеләр яңа йорт сала.
Тайгаларда йөри геологлар,
Башларына бозлар яуса да.

Галәм корабларынстарт ала,
Ир-егетләр диңгез кичәләр.
Безнең чорда каһарманлык кыла
Ихтыярлы, көчле кешеләр.

Тормыштагы бөтен могҗизалар
Әүвәл уза кеше кулыннан.
Яз ташкыны булып, сихри моң
Җаныбызга килеп кагылган.

Иҗат үрләренә атлаганда,
Канатланып тибәсең, йөрәк.
Безнең тантанага шаһит булсын,
Заманга тиң матур җыр кирәк.

## БУРАЗНАЛАР

Кара чәч толымы сыман ята
Басу буйлап узган буразна.
Каш өстенә кулларымны куеп,
Карап торам, туктап беразга.

Ана куенындагы бала төсле,
Тоям җирнең туфрак җылысын.
Язмышымны сиңа бәйләгәнгә,
Мәшәкатьнең бирдең зурысын.

Таң атса да, шәфәкъ батса да, шул
Буразнага төшә нурлары.
Баш өстендә канатларын кагып
Дәртләндерә тургай җырлары.

Буразналар башын ерак салган —
Күз күреме җитмәс очына.
Үрләреңә атлап менгән саен,
Басу өсте киңрәк ачыла.

Орлыкларым тигез шытар микән —
Күп сораулар белән борчылам.
Буразнада язгы күкрәүләрне,
Ләйсән яңгырларын каршы алам.

## ТАҢНАР ЕЛМАЯ ОФЫКТА

Таңнар елмая офыкта,
Сандугачлар сайрады.
Калтырап куйды агачлар,
Яфраклар да шаулады.

Бөдрәләнеп, су читеннән
Вак дулкыннар йөгерә.
Чәчәкләр таҗын үбәргә
Якты нурлар үрелә.

Шәүләләр югала тәмам,
Тоныклана тирә-юнь.
Хезмәт таңнары балкыды,
Иминлеген телимен.

Йолдызлар сибелгән төсле,
Үләннәрдә чык яна.
Күл өстендә төнбоеклар
Күзләрен ача яңа.

Сокландырган изге сәгать,
Көнгә керәсең, илем.
Таң уята табигатьне,
Беләдер, бәлки, телен.

## ИКМӘК

Мичтә пешкән икмәк исе чыкты,
Тәмле тоелганга тансыкмы?
Безнең буын егетләре күрде,
Татып үсте авыр ачлыкны.

Башкалар күк икмәк кадерен беләм,
Яшьтән тоттым сабан үрелеп.
Миңа калдырмаган эти әзерен,
Яшәмәдем һич тә иренеп.

Мәҗлес күреп кунакларда йөрим,
Күңел ачам шаулы туйларда.
Сый-хөрмәте арта икмәк белән,
Табыннарга кирәк куярга.

Икмәк булса, дәртле җырлар туа,
Балкып китә йөзләр, яктыра.
Кан да уйный нәҗәгайлар сыман,
Куәт-көчен тәннең арттыра.

Мохтаҗлык юк, муллык арта гына,
Исәпләдем бары үткәнне.
Мичтә икмәк пешә, чәем кайный,
Бәйрәм итәм өйдә бу көнне.

## ТУГАН ИЛ

Юлларым еракка илтә,
Зур икән Туган илем.
Икмәге-сые бетмәс күп,
Бөгә өстәлләр билен.

Шаулы нарат урманнарың,
Көмеш сулы күлләрең.
Бишектә чакта ишеттем
Дәртле тургай телләрен.

Күрдем таулар горурлыгын,
Басуларның киңлеген.
Афәтләрдән саклап калыйк
Туган ил иминлеген.

Җирем яшьлегенә кайта
Таллар бөредә чакта.
Дәрьяларың көйләп җырлый,
Туган ил, синең хакта.

## КЕШЕ КӨТӘ

Кем генә шатлык кичерми,
Кем генә кайгы күрми,
Кем генә суга төшмәгән,
Кем генә утка керми?

Максатына ирешү юлын
Кеше төрлечә эзли.
Акланмый кала өметләр,
Гомер үткәнен сизми.

Югалту да, табыш та бар,
Бәйләнгән язмышыма.
Күп чакта кеше сәбәпче
Үзенең ялгышына.

Күзне ачып йомган чаклы,
Вакытлар алышына.
Ак җилкәннәр корып булмый
Тормышның агышына.

Яшәү — серле, төшенергә
Һәркемгә насыйп түгел.
Үз бәхетен гомер буе
Ышанып көтә күңел.

## АВЫЛ ҖАНЛАНА

Иртә чыга көтү, урам тулып,
Болын якка табан юл ала.
Үләндәге чыклар җем-җем итә —
Куаныч хәл, күңел юана.

Бал кортлары арлы-бирле оча,
Үз эшенә бердәм тотына.
Каз-үрдәкләр иртүк каңгылдаша,
Шау-шуларга тынлык йотыла.

Бакчаларда чәчкә түтәлләре,
Кояш нурларына коена.
Авылымның ямьле иртәләре
Җанга рәхәт булып тоела.

Таңнан торып йокыларын бүлә,
Халык чыга бар да басуга.
Күк өстендә тургайларым җырлый,
Юллар ята офык очына.

Табигатьнең серле бер мәлендә
Моңнар, төсләр, гөлләр яңара.
Тормыш мәшәкате күкрәү сала, —
Иртә белән авыл җанлана.

## КҮЗЛӘР

Күреп беләм: күзләр төрле була —
Коңгырт, кара, зәңгәр, яшеле.
Кояш кебек балкып көлгәне бар,
Уйнап торганы бар яшене.

Тормыш утын, ялкыннарын алган —
Күзләрнең мин беләм төрлесен,
Шатлыгын да, кайгысын да җыйган,
Югалтмаган ләкин үз төсен.

Мин күзләрдә яла, мәкер күрсәм,
Борчуларга сала гайбәте.
Намуслылар гадел бәяләнсә,
Алтыннан да артык кыйммәте.

Кайчак телләр урынсыз да була,
Бары күзләр төгәл аңлата.
Үз вакытын, җаен белеп кенә
Сөйләшә бит кеше ымлап та.

Диңгез төбе кебек тирән икән —
Күзләр җыя барын үзенә.
Хыяллар да, өметләр дә сыя —
Нурга тулы олы хәзинә.

## ТӘҮГЕ КҮКРӘҮ

Баш очыннан узды язгы күкрәү,
Сискәндерде мине, тетрәтте.
Бөтен шикне, бөтен шомны куып,
Кыюлыкка шулчак өйрәтте.

Уйсулыкта дулкынланып ята,
Уймакланып уйный кар суы.
Көчле ташкын белән бергә акты
Җилкендергән күңел ярсуы.

Вак-төякләр шөбһәсеннән арынып,
Уйларымнан тәмам бушанам.
Буйга җитеп килгән кыз шикелле,
Язмышларга мин дә ышанам.

Бәгъремне телгән борчуларга,
Иң соңгысы булсын — чик куям.
Бу язларым яшьлегемнән кайтты,
Тәүге күкрәүләрне шат тоям.

## ТАРТУ КӨЧЕ БАР

Болын сукмагыннан чыклар ярып,
Керфек сирпеп гөлләр таҗына,
Кәефләнеп, мин хушланып кайтам,
Җан азыгы — бары наз гына.

Алларымда җәйрәп киңлек ята,
Күк чатырын ачкан — сокланам.
Туган җирем, синең туфрагыңда —
Минем язмыш, минем шатлыгым.

Күзләремдә күкнең зәңгәрлеге,
Җитез җилләр хуш ис тарата.
Офык читләрендә ымсындырып,
Тыныч кына сызылып таң ата.

И, күңелем, бетмәс гүзәллекне
Энҗе-мәрҗән итеп җыясың.
Бар нәрсәне караш капшап үтә —
Ай, йолдызын булсын, кояшын.

Көн кояшлы булса, төнем айлы,
Үкенечкә калмый хаҗәтем.
Дөнья тормас сукыр тиенгә дә,
Татымасаң тормыш ләззәтен.

Болыннарга чыккач ямен күрәм —
Күзне камаштырган төсе бар.
Хушландыра, сабырлата белә —
Җир куәте, тарту көче бар.

## ЭҢГЕР ТӨШКӘН МӘЛ

Кичке эңгер төшкән мәл,
Тына яфрак алкышы,
Тауда уйный алсу нурлар,
Үрли шәфәкъ балкышы.

Җир өстенә тынлык ята,
Җаным гына шомлана.
Оясын җуйган кошчыгым
Бер ялгызы моңлана.

Серле дә миңа, гаҗәп тә,
Сәер күрәм бу хәлне.
Уйсулыкка томан төшә,
Шау-шу тына бу мәлне.

Көмеш тамчылар чылтырый —
Үләннән чыклар тама.
Арыган юлаучы сыман
Йокымсырый Җир-ана.

## ЙӨРӘГЕМ КЫҢГЫРАУЛЫ

Йөрәк кага күкрәк читен,
Кыңгырау сыман чыңлап.
Гомеремдә күптапкырлар
Карыйсың мине сынап.

Вакыт уза йөрәк аша —
Өнсез, эзсез калмады.
Чәчәкле болыннары бар,
Бар эремәс карлары.

Җил-давыллар кинәт куба,
Ташкыннар шаулап таша.
Килер елларны каршылыйм
Якты таңнарым аша.

Томан пәрдәсен таратты,
Төн карасын эретте,
Шомлы, шөбһәле чагымда
Көч-ышаныч терелтте.

Йөрәгем — көмеш кыңгырау,
Чың-чың итеп чыңлады.
Күкләргә мине күтәрә,
Белеп кенә чаманы.
Сабыр, түзем, чыдамлы.

## АГЫН, КҮГЕН КҮРДЕМ

Агын да бар күргән, күген дә бар,
Утка кердем, суга төштем мин.
Ачысын да, төчесен дә тоям —
Олы чүмеч белән эчтем мин.

Тормыш өресен дә җыеп эчтем,
Нужа калачын да ашадым.
Кул кизәнеп якалашкан чакта
Дон-Кихотка инде охшадым.

Яшәү кануннары төрле була,
Бар михнәтен, зарын күрсәтә.
Дус-иш булып башта кыландылар,
Үрелделәр аннан күсәккә.

Миңа дөнья гел түгәрәк төсле,
Туп шикелле итеп тибәргә.
Ярыктан да кызлар кызык таба,
Исәп тотам мин дә көләргә.

Төрле хәлгә тарып яшәгәчтен,
Күргәнем бар әзме куркакны.
Искән җилгә каршы күкрәк куеп,
Шүрләмичә атлыйм — беркатлы.

Үлчәмичә кайчак сөйләшкәндә,
Авызымны өтәм, пешерәм.
Мин юаш та түгел, сабыр итәм,
Күп могҗиза баштан кичерәм.

## ТАУЛАР ИЛЕ

Күккә ашкан күк тауларга мендем,
Ак болытлар йөзә түбәндә,
Йолдызларга арам якыная,
Галәмнәргә караш төбәлә.

Бер горурлык хисе тоям җанда,
Йөрәк әйдәләде биеккә.
Таулар иле гаҗәп мәхәббәтле,
Иярләндем тәүдә күреп тә.

Үз төсе бар монда һәрбер ташның,
Җилләр җитез, сулар йөгерек.
Саф һаваның шифалары тия,
Сырхау кеше китә терелеп.

Үрләп минә сукмаклары урап —
Күреп калдым бу як гүзәлен.
Шарлавыклар ташып аккан ярдан
Карап тордым яшел үзәнен.

Таулар иле, тойгыларга — канат,
Ашкындырасың бит белеп син.
Бөркетләрең белән горурсың да,
Кыяларың белән биек син.

## ҖИР ХӨКЕМЕ

Җирнең гаме, яме бетә бара,
Хәзинәсе аның талана.
Заводлардан чыккан кара сөрем
Илем күге буйлап тарала.

Яшел төсе җирнең җуелмасын,
Чишмәләрнең суы кипмәсен.
Төшенәлми кеше үз хәленә,
Яшәү кадеребез китмәсен.

Сайрар кошлар ояларын тапмый,
Кунган тирәкләре киселә.
Без күрмәсәк хәзер җир хәстәрен,
Кискен хөкем кылыр кешегә.

Галәмнәргә оран салып дәшер,
Яшен яшьнәп, күкләр күкрәтер.
Гамьсез булып яшәгәннәр өчен
Җир анабыз җанны тетрәтер.

Табигатьтә сизгер сакчыллык бар,
Вакытлары җитеп, кисәтер.
Җил-давыллар кубар, туфан калкыр,
Бер булса да көчен күрсәтер.
Хәлләр мөшкел: безне нишләтер?..

## МИН ШИКЛӘНӘМ

Күзне ачып, күзне йомып карыйм,
Сорауларга җавап эзләдем.
Ачуларым кайнап ташып чыкты,
Тешләремне кысам, түзмәдем.

Урамнарда киллер кеше ата,
Вәхшиләрнең кискен хөкеме.
Явызлыкка богау салынмаган,
Хәвеф-хәтәр яный һәркөнне.

Хәерсез зат, имансызлар үрчи,
Фәхишәнең тота тулгагы.
Җаным риза түгел берсенә дә,
Фаш итәмен бары булганны.

Кайсы заман кешеләре соң без —
Уңга карыйм, карыйм сулга да,
Нигә ямьсез кыланабыз, дисәм,
Җавап бирми беркем сорауга.

Йөз яшәрдәй харап кылансак та,
И, гомерләр кыска, чикләнгән.
Газиз башым тагын ни күрер дип,
Иртәгәсе көнгә шикләнәм.

## БОРЧУЛАРЫМ БЕТМИ

Юанычлар табалмыйча,
Бу көннәрдә борчылам.
Кайгыларым баштан ашты,
Язмышыма ачынам.

Учак сыман дөрләп янам,
Тетрәнгән сәгатьләрем.
Ачыклап бетереп булмый,
Күптөрле сәбәпләрем.

Тарта туган җир туфрагы,
Җирсүгә юк чаралар.
Төзәлми, өстәлеп тора
Йөрәгемә яралар.

Хыянәтче мәкерлеген,
Вәхшилеген аңладым,
Сөюдә алданган кыздай,
Юк, тормышта уңмадым.

Таллар кебек бөгеләмен,
Җавапсыз күп сораулар.
Башым түбән иелмәде —
Булмас соңгы сынаулар.

## АЙ ТОТЫЛГАН ТӨНДӘ

Шом басты тирә-юнемне,
Төн карасы күземдә.
Күмер төсенә кергән ай,
Балкымый күк йөзендә.

Сукмак салып кыр өстенә,
Ай күктә көлеп йөрми.
Абалап авыл этләре
Бу чакны бер дә өрми.

Әллә өнен югалтканмы
Чишмәнең агышлары?
Ишетелми урамнарда
Җыр-гармун тавышлары.

Ходай үзе генә белә
Галәмдә ни буласын.
Өй түрендә, шөбһәләнеп,
Әби укый догасын.

Сәер дә, серле дә сыман
Ай тотылган бу мәлдә.
Күк ишелеп төшәр сыман —
Тәүбәгә кил, и бәндә...

## ГОМЕР ЙОМГАГЫ СҮТЕЛӘ

Гомер йомгакларын сүтә-сүтә,
Чыгып житәм, ахры, очына.
Кул тимәгән күпме эшләрем бар —
Ах, йөрәгем әрни, борчыла.

Гомер агышларын туктатырлык
Җирдә белмим бирәр көч барын.
Серләремне бары сезгә сөйлим,
Сез аңларсыз мине, дусларым.

Таш стена сыман басып тора,
Чыгалмыйбыз вакыт чикләрен.
Бәхет көтеп гомер кичерәбез,
Иңгә сала тормыш йөкләрен.

Белеп, күреп барын яшәсәк тә,
Дөнья фанилыгы онтыла.
Хыял-өметләр дә беркөн кинәт
Челпәрәмә килеп ватыла.

## ЯЛГЫЗ КАЕН

Ялгыз каеннар моңлана,
Тол хатындай сагышлы.
Еракларда ишетелә
Зар елаган тавышы.

Караңгы төннәрдә каен
Ялгызы шомланадыр.
Башларына боз яуса да,
Барыбер чыдагандыр.

Кояш нурларын күрергә
Уфтанып яшәгәнме?
Болыт каплагач күкләрне,
Яшеннәр яшьнәгәнме?

Сары көя яфраклары,
Ялкыннар кабынганмы?
Калтыранып ялгыз тора,
Давыллар кагылганмы?

## УРМАННАРДА ЙӨРИМ

Каеннарың бөдрә, талың чуклы,
Шомыртларың ап-ак күлмәкле.
Күгең зәңгәр, аланнарың яшел,
Һәр бизәгең, урман, кыйммәтле.

Мәрмәр колонналар кебек тора
Каен агачлары еректан.
Язы килгән купшылыгы белән,
Якты төсләр җәен яңарткан.

Имәннәргә яшен уты тигән,
Ветераннар кебек олылар.
Оркестрлар уйный, монда җырлый
Урман солистлары — былбыллар.

Шаулаганда дулкын уйнатасың,
Тыңлашәсең олы диңгезгә.
Озын сукмагыңнан атлап киләм —
Яшәү дәрте җанга тергезә.

Серләреңне ачып бетермисең,
Ямьнәрең күп, үзең хәзинә.
Сиңа киләм, урман, гомер буе,
Вакыт таптым исә әз генә.

## КИЛӘЧӘКНЕ КҮЗАЛЛЫЙМ

Колагымнан китми: гөжләп торган
Заман шау-шуына күнектем.
Аянычлы хәлләр туып тора,
Ихтыяр, көч табар кебекмен.

Утлы өермәләр булып дөрли,
Сары шәфәкъ ялый күк читен.
Дөнья афәтеннән арынмаган —
Сискәндерә, тормыш бик читен.

Күк йөзләрен каплап, метеорлар,
Яңгыр булып, өскә яумасмы?
Нейтроннар, атомнары шартлап,
Газиз җирем көйрәп янмасмы?

Боз таулары эреп акса нишләр,
Җиребезне сулар басмасмы?
Җир, түгәрәк футбол тубы кебек,
Орбитадан чыгып очмасмы?

Мең сорауга бер җавап та тапмыйм,
Томан баскан тоташ күз алдын.
Учак ягам яшәвемне раслап,
Учым белән утлы куз алдым.

Язлар — язча, көзләр — көзчә килми,
Киләчәгем билгесез һаман.
Сиздерә дә, кисәтә дә сыман:
Әллә җитә микән ахрызаман?

## ТҮЗӘРСЕҢМЕ, ЙӨРӘК?

Теләкләргә ирешмичә калдык,
Ашкындырган хисләр сүрелде.
Сәламемне сиңа җиткермәсләр —
Яфрак булып җиргә сибелде.

Юллар очы килеп кушылмады,
Ике ярда басып торабыз.
Күпер салынмады, бик аяныч,
Тоташмады безнең арабыз.

Өмет өзеләсен мин төшендем,
Борчыласын җанның озакка.
Мөхәббәтем белән түләп алдым,
Түзәрсеңме, йөрәк, газапка?

Акланырга сәбәпләрен таптык,
Вәгъдәләрең очты җилләргә.
Кайнар яшьләр күзне томалады,
Авыр уйлар төште иңнәргә.

Мәхәббәткә җиңел караганбыз,
Бәгырьләрне телеп тилмертә.
Чын ярату, сөю дәрте булса,
Сырхау кешене дә терелтә.

## АВЫЛЫМА КАЙТСАМ

Авылыма кайттым исә,
Болыннарны урыймын.
Җаныма сабырлык бир, дип,
Туган җирдән сорыймын.

Печәннәр чапкан җиремсең,
Атлар саклаган урын.
Юксынуга чара тапмый,
Сагынып кайттым барын.

Балтырган, какы, кузгалак
Җыямын учларыма.
Утлар тергезеп җибәрәм —
Дөрләсен учагымда.

Җир җылысын, юмартлыгын,
Тоям аның хуш исен.
Атлаган сукмакларыма
Гөл-чәчкәләр түшисең.

Чит якларда гомер үтә,
Кайталмыйча кичектем.
Тургайларым исән икән, —
Сайрауларын ишеттем.

## МИН КӨЧ ТАБАМ

Күз яшьләрен, дөнья, түктерәсең,
Рәнҗү белән гомер итәмен.
Газабыңны күреп яшәгәчтен,
Нинди рәхим синнән көтәмен?

Этләр туен күреп гомер үтә,
Тормыш ләззәте юк бертөрле.
Ызгыш-талаш белән узган көннәр
Йөрәгемне талап бетерде.

Юанычлар эзләп карасам да,
Табалмадым аның дәвасын.
Биләүгә дә, кабергә дә сала,
Фани дөнья адәм баласын.

Табигатьнең үз кануны белән
Үскән гөл дә корый вакытсыз.
Гомеремдә күп югалту күреп,
Көйрәп яндым утсыз, ялкынсыз.

Бу заманда яшәү җиңелмени,
Мин көч табам иҗат эшемнән.
Йөрәк кенә түзсен шартламыйча
Көнчел кешеләрнең үченнән.

* * *

Дөнья хәзинәләр вәгъдә итә,
Ашыктыра, әзме йөгертә,
Борын суы тарткан малайларны
Усал ирләр итеп өлгертә.

Бишегенә салып тирбәтә дә,
Җәзаларын биреп тилмертә.
Мыштым гына йөргән бәндәләрне
Кыюлата, хәтәр телле итә.

Көлдерә дә белә, елата да,
Аңламассың кайчак дөньяны.
Берәүләргә дан-дәрәҗә бирде,
Берәүләрне озак кыйнады.

Үз урынына куя вакыт барын,
Исәпләшми дөнья, алдалый.
Максатына кеше җитә алмый,
Бу тормышны кайчак аңламый.

## ЯР БАШЫНДА КУШ КАЕННАР

Бүә яр өстендә куш каеннар,
Колач ачып, җәя канатын.
Җил-давыллар килеп кагылса да,
Берни булмаган күк тора тын.

Күкләр күкрәп, яшен яшьнәгәндә,
Куш каеннар курку белмәде.
Сәхрә уртасында горур басып,
Үзе белгән җырын көйләде.

Кулны болгап дәшәм каеннарга,
Ераклардан күреп танырсыз.
Сары сагышларга бирешмисез,
Сеңелләрем кебек сабырсыз.

## ХЕЗМӘТ БӘЙРӘМЕ

Халык чыккан сабантуйга
Ямьле болын буена.
Җырга-моңнарга күмелгән,
Бәйрәм шаулы тоела.

Офык читеннән күренә
Ярышка чыккан атлар.
Йөрәкләрне җилкендергән,
Шатлык кичергән чаклар.

Гармунчылар гармун уйный,
Кызлар биергә төшкән.
Уңганнар күп, матурлар күп,
Авылда туып үскән.

Ир-егетләр көчен сыный,
Мәйданда көрәш бара.
Биек колгалар башында
Чиккән сөлгеләр тора.



2 — 676

Быел кемнәр алыр икән
Сабантуй бүләкләрен?
Ярыш чәме батырларның
Җилкетә йөрәкләрен.

## КОЯШ

Офыклардан көлеп кояш чыга,
Күк юллары буйлап үреләә.
Кошлар кебек бер талпынып куя,
Менеп баскач галәм түренә.

Бар җиһанга якты караш сала,
Бөтен дөнья балкып яктыра.
Табигатькә яшәү көче бирә,
Гүзәллеген, назын арттыра.

Мәңге сүнмәс кояш балкып яши,
Изгелекле, һәрчак шәфкатьле.
Язлар алып килә кешелеккә,
Нинди рәхим, көч бар шулхәтле?

Күк өстенә көлеп кенә чыкты,
Минутына соңга калмады.
Ничә гасыр якты нурын сибә,
Ничек икән бер дә арымады?

Ямьле җәйләр, кышлар алып килә,
Сокландыра җирдә һәркемне.
Нишләр икән дөнья, әгәр инде
Чыкмый калса кояш беркөнне?

## МИНЕМ ӨЧЕН

Минем өчен көлеп кояш чыга,
Таңнар белән яңа көн туа.
Җаннарыма яктылыгын сирпеп,
Күңелемә дәртле моң тула.

Минем өчен чишмә гөрләп ага,
Бөтен сусауларым басыла.
Урап кайтам сәхрә-кырларымнан,
Иркен кочаклары ачыла.

Минем өчен ап-ак карлар ява,
Кара җир өсләрен агартып.
Ел фасылы гел үзгәреп тора,
Уйларымны һәрчак яңартып.

Минем өчен, җирем, хәзинәң бар,
Алтын тавың, көмеш күлләрең.
Бәхет-шатлык юрап кошлар сайрый,
Хуш ис сибә асыл гөлләрең.

Минем өчен нигъмәтең күп, җирем,
Ризыкларга мул табының бар.
Кешеләргә Ходай ирек куйган:
Оҗмахы да, тәмугы да бар.

## ХАТИРӘЛӘР ЯҢАРТАМ

Тын сукмаклар буйлап ялгыз атлыйм,
Уелып калган йөргән эзләрем.
Чирәм өсләрендә аунап үскән,
Малай чагым, сине эзләдем.

Сабантуйлар кебек гөрләп узган
Яшь вакытлар калган еракта.
Тирәкләрем шаулый берни белми,
Уй-сагышлар салып йөрәккә.

Күп гомерләр үткәч, тагын килдем,
Якты хатирәләр яңартам.
Таныш кырлар, таныш сукмакларым,
Искән җилен дә мин яратам.

Эзләремә басып кемнәр килер,
Яшәү кануннарын мин беләм:
Көзләр җиткәч, агач яфрак коя,
Карлар явар тиздән — мин булмам...

## ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

* * *

Ижат учагында дөрләп янам,
Күңелләргә үрли ялкыны.
Сезгә бүләк итәр хәзинәм бар,
Мин яратам, сөям халкымны.

* * *

Бер иптәшнең сәер кыланашы,
Түрә булгач, ханга әйләнде.
Эт шикелле әрсез, гамьсез кеше,
Күргән саен миңа бәйләнде.

* * *

Мәшәкатьле тормыш, яшьлек дустым,
Күршәлмичә үткән еллар бар.
Ефәк тасма кебек өзелеп калган,
Арабызда яткан юллар бар.

* * *

Авылга килен төште —
Кыңгыраулы туй аты.
Гармун уйнаган егет
Төрле уйлар уйлатты.

* * *

Төзәлмәслек йөрәк җәрәхәте,
Тоз салалар һаман ярама.
Еллар арык, чуар заманасы,
Озын гомер, кәккүк, юрама.

* * *

Җырларымда юаталсам икән
Сагышланган кеше йөрәген.
Күңеленә керсәм юллар табып,
Шунда булыр минем кирәгем.

* * *

Үзәннәрдә өнсез тынып калган,
Көзнең сарысына буялган
Тал-тирәкләр үксеп бәргәләнә —
Кошлар очып киткәч оядан.

* * *

Дөнья малын, мөлкәтләрен җыймыйм,
Миннән калмас байлык өелеп.
Ашап-эчтем, сөйдем дә сөелдем,
Яшәмәдем һич тә көенеп.



## АРЫШЛАРЫМ СЕРКӘ ОЧЫРА

Бер офыктан, карыйм, бер офыкка
Җәйрәп ята басу киңлеге.
Баш өстендә тургай җыр сузганда,
Дәртле моңнар били күңелемне.

Сөенечле хәбәр юллый төсле,
Арышларым очыра серкәсен.
Зур горурлык хисе, җанда туып,
Йөрәк кылларына чиртәсең.

Сары диңгез кебек алкынланып
Дулкын кага арыш басуы.
Куанычлы, сөенечле бу хәл,
Тансык кына аның шау-шуы.

Арыш серкәләре канатланып,
Кыр өстендә тынмый тирбәлә,
Күбәләкләр кебек очып уйнап,
Бөтерелә минем тирәмдә.

Буранлады арыш басулары,
Чәч-толымын җилләр тарады.
Игеннәрем уңган — күреп кайттым,
Шикле уйлар баштан таралды.

## КӨНЧЕЛЛӘР КҮП

Күңелем иркен, адашырлык,
Сәхрә-кырга тиңләшә.
Дус күреп йөргән кешеләр
Күп чак миннән көнләшә.

Эт шикелле әрсез булган
Беләм мин кешеләрне,
Таш ыргытып, ут йөгертеп
Көн күргән көнчелләрне.

Аккан чишмәне корытыр
Көнчелләр тапса көчне.
Бар булмышы, фигыле ни,
Мәкерле кара эчле.

Гайбәт өя якынына,
Күршесенә, дусына.
Дәрәҗәсе артамы соң —
Важныйлана, очына.

Кем итеп аны танырга —
Төрле битлекләр кигән?
Иманын сатып яшәргә
Безнең арага килгән.

## ВЕТЕРАННАР САНЫ КИМИ

Ветераннар саны кими бара,
Борчыласың, җаным, сагыштан.
Авылдашлар яу кырында калган,
Кайталмаган күпләр сугыштан.

Авылымда өч ветеран калды:
Күзсез, кулсыз, берсе аяксыз.
Кан түктергән, кеше гомерен өзгән
Сугыш чукмарлары оятсыз.

Ил чакыргач изге яу кырына,
Ир-егетләр читтә калмаган.
Сугыш фаҗигасен күргән халык,
Әмма олы Җиңү яулаган.

Ветераннар тыныч тормышта да
Алгы сафта, бердәм атлыйлар.
Олы җанлы, игелекне белә,
Гүзәл сыйфатларын саклыйлар.

Ветераннар сафы сирәгәя,
Югалтулар авыр күңелгә.
Батырларның һәйкәленә килеп,
Чәчәкләргә кирәк күмәргә.

## ӨМЕТ ЯЛКЫНЫ СҮНМӘСЕН

Күңел түрендә кабынды
Өмет учагым,
Йолдыз булып балкысын бер
Минем бу чагым.

Шәмнәр кебек дөрләп янсын
Давылда, җилдә.
Гауга, алыш беткәне юк
Мәңге бу илдә.

Хәтәр заманда туганмын,
Күптән аңладым.
Максатыма юл ярамын:
Тормыш, алдадың.

Матур яшәү теләге бар,
Шатлык кичерәм.
Арзан түгел аның хакы —
Таулар күчерәм.

Тормыш адым саен сыный,
Тоямын көн дә.
Өмет ялкыны сүнмәсен
Гомергә миндә.

## КҮРЕШҮ КӨНЕН КӨТӘМ

Хушлашмадың, китеп бардың,
Миндә уйлар кузгатып.
Күзләремнән югалганчы,
Карап калдым озатып.
Киттең уйлар кузгатып.

Син киткән якларда балкып,
Таңнар сызылып атты.
Җил, шаяртып, каеннарның
Яшел чугын таратты,
Миндә хисләр яңартты.

Сезнең яктан кошлар кайтты,
Тирәкләрдә кагына.
Юксынып яшимен хәзер,
Сагыш җанга кагыла,
Күңел сиңа табына.

Кабул итәм аткан таңны,
Кайнар сәламең итеп.
Өметләнеп мин яшимен,
Сөю язларын көтеп,
Гомерләр бара үтеп.

## ЗӘҢГӘР КҮЛМӘГЕҢНЕ КИ

Зәңгәр күлмәгеңне ки син,
Тегелеше килешле.
Күккә тәңгәл килә төсе,
Әллә икән бер ишме?

Күзләрең дә зәңгәр синең,
Диңгез кебек тирәндә.
Нинди сихри көчләре бар,
Карашларым төбәлә.

Көнең гел кояшлы тора,
Яшьлегең иртәсеме?
Сандугачлы язларыңны
Сагынып көтәсеңме?

Таулар, күкләр, дәрья сулар,
Биргән сиңа үз төсен.
Мәхәббәттә сыналырсың,
Табынырсың кем өчен?

Ки дә зәңгәр күлмәгеңне,
Көзге алларына бас.
Табигать биргән гүзәллек,
Фәрештәләргә син хас.

* * *

Эндәшмичә калам — көчем җитә,
Сүз куерту кайчак кирәксез.
Әйтүчеләр булыр куркак диеп,
Ничек яши кеше йөрәксез?

Гомер буе дәгъвәләшәм инде,
Яшәү өчен, бәхет хакына.
Хезмәт сөям, тормыш яратамын,
Мин бурычлы туган халкыма.

Күңел күгем бер бушанып кала —
Дусларыма барып акланам.
И, ходаем, күпме яман эштән
Арчалаган, мине саклаган.

Абынганда яки егылганда,
Кайчак төшсәм кинәт түбәнгә,
Кояш шаһит: күктән карап көлә,
Анам кебек әзер үбәргә.

## ДӨНЬЯГА ТУА БАЛА

Адәм баласын тугач та
Ак биләүгә төрәләр.
Иркәләп, назлап сөяләр,
Күз карашын түгәләр.

Ак бәхетләр, сөенечләр
Аңа карап юллыйлар.
Күргән төшен яхшылыкка,
Изгелеккә юрыйлар.

Халыкның шундый йоласы,
Килә ерак чорлардан.
Ефәк тасмалар шикелле
Йөрәкләргә чорналган.

Дөньяга туган баланы
Йолдызларга тиңлиләр,
Олы өметләр баглыйлар,
Изге теләк телиләр.

Исемен сайлап кушалар,
Бишек җырын җырлыйлар.
Йола-гадәтләр буенча
Сабый җанны зурлыйлар.

Иң татлы ризык бирәләр:
Икмәге тәмен беләм.
Тормыш кочагына ала
Сөюе, назы белән.

## ТӨРЛЕ ВАКЫТ МИЗГЕЛЛӘРЕ

Быелгы көз соңга калып килде,
Декабрьдә тәүге кар төште.
Мин юрадым бары хәерлегә
Таң алдыннан күргән бер төшне.

Төшемме соң, әллә өнемме соң,
Аеруы кыен бу мәлне.
Акыл аек, күңел бушап калган,
Уйлар очы кат-кат бәйләнде.

Кошлар очты җылы якка күптән,
Агачлар да түгел яфракта.
Туңган үләннәрне эретерлек
Җир җылысы җитми туфракка.

Кыр өсләре иркен, бушап калган,
Сискәндергән анда өн-тын юк.
Үткән җәйнең матурлыгын исләп,
Мөмкин түгел һич тә онытырлык.

Төрле була вакыт мизгелләре,
Килә-китә җәе, кышы да.
Мәңгелеккә беркем килмәгән ич —
Кунак кына җирдә кеше дә.

## АПРЕЛЬ ҖИЛЕ ИСӘ

Кыйбла яктан җылы җилләр исә,
Агач бөреләре биләүдә.
Ил өстенә якты язлар килде,
Мәрхәмәтле кояш, көл әйдә.

Көмеш чылбыр кебек сузылган да,
Киек казлар кайта ерактан.
Ләйсән янгырлары уза шаулап,
Язгы күкрәүләрне яратам.

Кояш күктән балкып көлгән мәлне
Ялкын үрләп, җирдә кабына.
Аккош каурыйлары кебек йомшак
Апрель җиле килеп кагыла.

Күлләвекләр, гөрләвекләр шаулый,
Гөрләп аккан чагы ташкынның.
Язмышымның беләм үзгәрмәсен,
Якты язларыма ашкынам.

Апрель җиле йөри илләр буйлап,
Зәңгәр бозлар ага дәрьяда.
Күзен ачып кояш нурларына,
Бөре исе аңкый дөньяда.

## КЕШЕ РӘНҖЕМӘСЕН

Кеше каргышыннан куркам;
Рәнҗүләре төшмәсен.
Йөрәгемә сорау бирәм:
Хаксызлыктан нишләрсең?

Төрле хәлләр баштан уза,
Белмисең күрәчәкне.
Бәхетле, шатлыклы итеп,
Көтәсең киләчәкне.

Кайгы болытлары йөзә,
Ага хәсрәт дәрьясы.
Тормыш казанында кайныйм —
Тыныч түгел дөньясы.

Кар-бураннарга юлыктым,
Ташу суга бүлендем.
Сер бирмәдем, уфтанмадым,
Авылымда бер идем.

Арык еллар читләмәде,
Барын хәтергә алам.
Хаталансам, гөнаһлансам,
Ярлыкар бары Аллам.

## РӘХМӘТЕҢНЕ КҮРМИМ

Ерак галәмнәргә аваз салып,
Йөзгә бәреп салкын җил исте.
Дөнья, синең рәхмәтеңне күрмим,
Кан-яшьләргә тулы җир өсте.

Ыңгырашам, сискәндерә йокым,
Куркыныччлы күргән төшем дә.
Иман, әдәп белми торган заман,
Рәхим, шәфкать беткән кешедә.

Кара шәүлә булып арттан йөреп,
Бәла-казасы да сагалый.
Шатлыкларым бер төш кенә кебек,
Кайгыларым килә сорамый.

Яшен ташы сыман йөрәк янып,
Әйләнәсең кара күмергә.
Юлларыма ятлар киртә кора,
Каршы исте җилләр гомергә.

Тормыш сукмагымда ни күрсәм дә,
Язмышым дип кабул итәмен.
Шатлыгымны, кайгыларны алып,
Фани дөнья, синнән китәм мин.

## ХАЛЫК ЫШАНА

Алдак лозунглар урамнарда
Якты киләчәккә өндәде.
Партбилетлы юха, ялагайлар
Ил хакиме булды элгәре.

Җирдә оҗмах төзүчеләр без, дип
Ышандырды алар халыкны.
Буш вәгъдә, ялган вәгазьләрне
Күп ишетеп, кеше ялыкты.

Кызык уен итеп карагандай
Кызганмыйлар кеше язмышын.
Гаделлекне, азатлыкны яклап,
Башын салды ирләр азмы соң?

Ил башында торган зур түрәләр,
Үзгәртәбез диде дөньяны.
Мәкер белән төрле юл сайлады,
Нәфселәште, байлык җыйнады.

Кемнәр тагын әмер бирер икән,
Нинди хәлләргә соң төшәрбез?
Эт өрсә дә халык ышана бит,
Килер көнне уйлыйм: нишләрбез?

## КАБЕРЕҢӘ ЧӘЧКӘЛӘР КУЯМ

Кабереңә мин чәчкәләр куям —
Болыннардан җыеп китердем.
Йөрәгемдә калган юксынуым,
Сагышларым давыл күтәрде.

Син йоклыйсың җир йокысы белән,
Дөнья мәшәкате калмаган.
Юк, белмисең, сизмисең дә, тормыш
Әзме кешеләрне алдаган.

Икәү печән чапкан тугайларны
Урап килдем, дустым, яныңа.
Күксел таулар, сулар эчкән чишмәң —
Барысы да сине сагына.

Назлы чәчкә кебек гомерең синең
Бик вакытсыз кинәт өзелде.
Искән җилгә һәрчак каршы бардың,
Кызганмадың нишләп үзеңне?

Күзаллыймын соңгы минутыңны,
Юлларыңның монда азагы.
Көч җитәрлек сабырлык бир, ходай,
Югалтуның чиксез газабы.

## МИН ДӘ ХУШЛАШЫРМЫН

Күз йомылыр беркөн мәңгелеккә,
Гәүдәм талыр тирән йокыга.
Өнсез генә хушлашырмын шулчак,
Ятимлеген тояр йортым да.

Уйчанланып калыр Сакат тавы,
Чишмәләрем моңсу җыр көйләр.
Өй артында үскән каеннарым
Минем хакта, белмим, ни сөйләр.

Ишек ачкан чаклы гына булды
Бөтен гомеремнең узганы.
Сибелеп тә, чәчелеп тә калды,
Әйтерсең лә, юллар тузаны.

Җир куены җыя кешеләрне,
Дөнья фани нигә бу хәтле.
Йөз яшәгән адәм балалары
Язмышлары белән бәхетле.

Йөрәк күнмәс, ышанасы килми:
Тере калырмын күк ничек тә.
Тик вакытны кичектереп тормас,
Килеп шакыр әҗәл ишеккә.

## ЭТЛӘР ӨРӘ

Төрле яктан этләр өрә,
Юлга чыга абалап.
Игелекле кешеләр күп,
Мине ала аралап.

Мәхлукларга нәрсә җитми:
Өрә дә өрә генә.
Әллә бөтен ачуларын
Күрәләр миннән генә.

Явызлыкны, вәхшилекне
Тоямын адым саен.
Өзгәләп ташларга күптән
Көтәләр бары җаен.

Күзем кызмый, тарлыгым юк,
Кемнең дә кәсебенә.
Таш ыргытып, сүз кушмадым
Акбайлар нәселенә.

Юлыма өреп чыгасыз,
Юк, сезне сагынмадым,
Этләргә табынмадым.
Якты көнем, үз сукмагым,
Бер читкә сугылмадым.

## ХАТЛАР ЯЗАМ

Хатлар язам тагын сиңа,
Хәлләремне аңларсың.
Язмыш кайларга ташламый,
И, бу адәм баласын.

Арабызда хатлар йөри,
Серләрне уртак итеп.
Яшь гомер уза сызланып,
Күрешү көнен көтеп.

Татлы йокылар бүленде —
Төшемдә сине күрдем.
Җитәкләшеп синең белән,
Болыннар буйлап йөрдем.

Кайнар тойгылар кичерәм,
Кадерле минутларым.
Күңел түрендә саклармын,
Гомергә онытмамын.

Йөрәк җылысын сизәрсең,
Хатларымны укысаң.
Иңнәреңдә канат үсәр,
Сөю хисен татысаң.

Син аңларсың, мин ышанам,
Яшермим һич тә барын:
Шатлыгымны уртак итәм,
Үземдә калсын зарым.

## ӨНСЕЗ КАЛАМ

Төнбоек кебек йомылам,
Эндәшми өнсез калам.
Сабырлыгымны җыямын,
Җир-анам, синнән алам.

Ялгыз башым, моңланасың,
Нихәл итим, юк чарам.
Гомеремә төзәлмәслек
Күңелдә калган ярам.

Кошлар кебек талпынамын,
Талганчы канатларым.
Меңнәргә охшаш язмышны
Үземчә кабатладым.

Ятлар теленә кергәнмен,
Хаксызлыктан кимсенәм.
Дусларның да төрлесе бар,
Шөгылемнән көпсенгән.

Сүзсез калган минутымда
Кем мине дөрес аңлар?
Шик астына куеп тагын,
Чыгарыр нинди карар?..

## ҖИР ГАМЕ

Җәйнең ямьле чагында,
Табигать кочагында
Аккошлар күлгә төшә,
Җир җиләкләре пешә.

Бии күлләр камышы,
Ишетелә су агышы,
Моңлы кошлар тавышы,
Бетә күңел сагышы.

Күл өстендә якты нур,
Тау кадәр шатлыгым зур.
Яшәүнең төп асылы —
Шаулы иген басуы.

Җәйләрнең бетмәс яме,
Эчкән суларым тәмле.
Туган җирем бер генә,
Назын тоям гел генә.

## СИЗДЕРМӘСКӘ ТЕЛИМ

Сиздермәскә, белдермәскә телим,
Тыныч көннәремне югалттым.
Көткән бәхет кошы килер кебек —
Күңелемне шулай юаттым.

Юллар тапмый адашып та йөрдем,
Тигез җирдә кайчак абындым.
Берәүләргә бик мөлаем булдым,
Берәүләргә каты кагылдым.

Үзем егылганда зарланмадым,
Гаебемне эзлим азактан.
Язмыш белән гел бәхәскә керәм,
Сызлаганда йөрәк газаптан.

Хыялларым татлы бер төш сыман,
Уйларымда калам кабаттан.
Сугылдым да, бәрелдем дә кинәт,
Канатымны мин дә канаттым.

Канатларым җиргә сугылса да,
Югарыга табан үреләм.
Фаҗигаләр күреп яраланам,
Тормыш сөеп, кабат терелэм.

## ГАРМУН ТАВЫШЛАРЫ

Кем уйнады күрекләрен сузып —
Гармун тавышларын тыңладым.
Тәүге күкрәүләрем урап кайтты,
Балкып китте яшьлек таңнарым.

Ташкын уртасында торып калдым,
Күңел бозларымны кузгатты.
Җанны жилкендергән моң-авазын
Йөрәк түрләремә озатты.

Сары сагышларны юып алды,
Күз алдымнан томан таралды.
Сулар чыкты кипкән чишмәләргә,
Шиңгән гөлләр кабат яңарды.

Бер уйныйсым килә гармуннарны,
Их, белергә аның телләрен.
Ишетергә моңлы тавышларын,
Урамнарда йөрим төннәрен.

**ГОМЕР ЯЗЛАРЫ**

Гомернең була язлары,
Бар аның көзләре дә.
Сагыну хисе сагышлы,
Чагыла йөзләремдә.

Сиздерә еллар үткәне,
Күп сулар аккан икән.
Ашкынып тормый йөрәгем,
Мин хәзер башка, бүтән.

Әүвәлгедәй тансык итәм,
Килер көнемне көтеп.
Яшен уты кебек уйлар
Күңелне ала өтеп.

Сәгате, минуты санлы,
Гомер һәрчак исәптә.
Җирдә яшәү куанычлы,
Газап-михнәт күрсәк тә.

Яңгырлар булып явамын,
Томан пәрдәсен ябам.
Гомер шулай уза икән —
Ал таңнар булып янам.

## ТӨНБОЕКЛЫ КҮЛЕМ

Туган җиргә матур бизәк өсти
Тал-тирәкләр, үскән гөлең дә.
Ай-кояшка карап күзен ача
Төнбоеклар зәңгәр күлемдә.

Җәйләр җитсә, күл буена киләм,
Бер горурлык хисе кичереп.
Яр читендә зифа камышлары
Назларыннан бии исереп.

Аккошлары ояларын корган,
Шаһит булдым шундый чагына.
Күк өстендә йөзгән ак болытлар
Күзге сыман балкып чагыла.

Су өсләре бөҗраланып тора,
Бер мизгелдә бар да төрләнә.
Күңелләрем кебек тирәнсеңдер,
Ялгыз бер сал талгын тирбәлә.

Күл янынннан үткән сукмакларым
Куәт бирер узган юлчыга.
Кай тарафка гына атласам да,
Баскан эзләремнән моң чыга.

## ТУГАЙЛАРДА ҖИЛӘК ҖЫЙДЫМ

Тугайларда җиләк җыям,
Сәхрәләр кочагында.
Яшел ялкыннар дөрләде
Җәйләрем учагында.

Җир җиләкләре пешкән мәл,
Җил тарата исләрен.
Бишекләрдә тирбәләм күк,
И, талпына хисләрем.

Сулышларым иркенәйде,
Тоям дөнья рәхәтен.
Мәрхәмәтле җәйләремә
Бетмәс олы рәхмәтем.

Тугайларны урап чыктым,
Тулганчы чиләкләрем.
Өметләрем акландылар,
Чын булды теләкләрем.

## ҖИР ҖЫЛЫСЫН ТОЯМ

Туган җирдән язмыш аермасын,
Тоеп яшим аның җылысын.
Күкрәүләре булып күкрәдең бер,
Ташкынына тиңдәш җырым, син.

Сокланам мин таңнар сафлыгына,
Аккан сулар бирә тавышын.
Басуларга чыгып урап йөрим,
Дулкын уйнатканда арышы.

Күксел таулар тарта карашымны,
Бер күрүдән гашыйк итәрлек.
Зәңгәр күлләрендә аккош назы,
Карурманнар монда җитәрлек.

Сәхрә-кырлар кебек күңел иркен,
Сыйган аңа шатлык, газабым.
Тургай җырларына мин дәртләнәм,
Басу түрләренә узамын.

Туган җирем туфрагына басып,
Хуҗасы дип аның хис итәм.
Игенчегә симфония уйный —
Башак җырын кырда ишетәм.

## ДӘФТӘРЕМДӘ КҮҢЕЛ ЯРСУЛАРЫМ

Озын төнем уза шигырь язып,
Нишлим, әти, килә ачуың.
Мин күчерәм кәгазь битләренә
Ташып чыккан күңел ярсуын.

Ата-бабам кылган кәсеп түгел —
Шигырь язып тамак туйдырмый.
Җиргә булган олы мәхәббәте,
Хезмәт дәрте аны тындырмый.

Яз башыннан чыгып кыр өстенә,
Җирен сөреп, иген үстергән.
Табыннары сый-хөрмәтле булган,
Җыр-моң белән гомер кичергән.

Сукмагымнан олы юлга чыктым,
Язмышыма үзем хуҗамын.
Мирас булып калган кәсебемне,
Шигырь язып, имеш, бозамын.

Игенчеләр нәселеннән килгән
Горурлану хисен зурларым.
Тургай телендәге моңнар булып
Яңгырасын илдә җырларым.

## СУКМАКЛАРДА ҮЛӘН ҮСКӘН

Бергә узган еллар калды,
Әйтерсең, ул төш кенә.
Шатлыгы да, кайгысы да
Булмаган күк һич кенә.

Безнең йөргән сукмакларда,
Яшел үләннәр үскән.
Язлар, көзләр килеп киткән,
Су аккан, җилләр искән.

Тормыш юллары аерды —
Икебез ике якта.
Сәбәпләрен эзләмик тә —
Ачу чыгардык юкка.

Язмыш хөкемендә калдык,
Яхшыны теләсәк тә.
Булган гаепне танымый,
Япсардык күрәчәккә.

Кош оясын туздырган күк,
Гамьсезлекне өнәдек.
Яшьлектә ачу-ярсуны
Йөгәнләргә белмәдек.

## МИН ТУГАЧ

Мин тугач та тәүдә кояш көлде,
Көн җылысын тойдым шул мәлдә.
Дөнья, синең наз-хөрмәтең күреп,
Гашыйк булып яшим мин әлдә.

Мин тугач та җилфер-җилфер җилләр
Канатларын кагып җилләнде.
Өй кыегындагы күгәрченнәр
Гөлдер-гөлдер гөрләп җибәрде.

Мин тугач та, яшәвемне раслап,
Сәгать теле чынлап чаң сукты.
Җәйләр яшел келәм җәйгән җирдә
Чәчәк исе булды бу чакны.

Мин тугач та, биләүләргә төреп,
Бишек җырын әни көйләде.
Гомер таңым балкып аткан мәлдә
Ак бәхетләр миңа теләде.

## ТАШКЕНТ

Ташкент күге якты, нинди аяз,
Күтәрелә кояш югары.
Җанга рәхәтлеген биреп торган
Җиләс җиле кая югалды?

Тирә-юньгә кайнар нур бөркелә,
Тынны курып ала әсселек.
Ниндидер бер аваз; иләhи моң,
Ераклардан тора ишетелеп.

Бакчаларда татлы йөзем пешә,
Аңкып килә ширбәт исләре.
Киң мәйданнар, озын урамнары,
Шау-гөр килә шәһәр өсләре.

Якын дуслар таптым монда килеп,
Юксынуны күңел сизмәде.
Музейларга кереп карап йөрдем
Узган чорның калган эзләрен.

Ташкент өчен күк чатырын ачкан,
Кояш йомарт биргән яктысын.
Мине кунак итте, кадер артты,
Зәмзәмнәрнең эчтем татлысын.

Бер төш кебек бөтен күргәннәрем,
Санаулы көн монда — төшенәм.
Гомерлеккә калсын синең ямең —
Күңелемә барын күчерәм.

## КӨТЕП ЯШИМЕН

Юксынуым беткәне юк,
Сагышлар басты күптән.
Дус-ишләремнең хәбәрен
Юлларга карап көтәм.

Кошлар кебек канатланып,
Таралдык ерак китеп.
Очрашуны, күрешүне,
Яшибез хәзер көтеп.

Табыннарга җыя алсам,
Үкенечләрем калмас.
Күңелләребез бушаныр,
Йөрәкләребез янмас.

Зәңгәр күкләрен томалап,
Болытлар куермасын.
Көтмәгәндә җил-давыллар
Канатны каермасын.

Хәвеф-хәтәрләр бетмәгән,
Шик сала минем уйга.
Җәйнең ямьле көннәрендә
Чакырам сабантуйга.

## БАБАМ МИРАСЫ КАЛГАН

Бабам тегермәнен корып,
Игелекле эш кылган.
Төш шикелле ул заманнар
Еракта торып калган.

Җире, суы, урманы да
Җитәрлек булган аның,
Кырда игеннәр үстереп
Арткан игенче даны.

Эш өнәгәч, уңган булгач,
Шөгыле белән откан.
Гөжләп торган умарталар —
Корт бакчасында торкан.

Бабамның өер атлары
Болында йөргән утлап.
Хәтерли авыл картлары,
Сөйлиләр аны мактап.

Мирас булып калган аның
Шөгыле, кылган эше.
Хезмәт җимешен мул җыйган
Тормышка гашыйк кеше.

## ҖАНГА ТЫНГЫ БИРМИ

Ата-бабам гомер иткән урын,
Йорт нигезен синдә корганнар.
Туган илем иминлеген яклап,
Әз булмаган җирдә корбаннар.

Каһарманнар эзе җуелмаган,
Һәйкәл булып калган бу чорга.
Еллар уза үз агышы белән,
Үткәннәргә йөрәк борчыла.

Төрле сорау, төрле уй башымда,
Хәвефле көн һаман уйлата.
Авыр фаҗигаләр төшкә кереп,
Йокылардан төнлә уята.

Киләчәккә күрәзәлек итмим,
Алдан күреп барын кем әйтә?
Бу галәмгә атом көче яный,
Ил язмышы җанны тетрәтә...

## УТЛАР БУЛЫП КАБЫНАМ

Утлар булып дөрләп янам,
Сулар булып түгеләм.
Мин тормышта яраланып,
Аннан тагын тереләм.

Ташкан сулар кебек шаулы,
Болганчык заманасы.
Мескен хәлендә түгелмен,
Һич килми зарланасы.

Яшәгәндә мохтаҗлыклар
Адым саен кисәтә.
Бу дөньяга кунак булып,
Азга гына килсәк тә.

Язмышлар якадан алып,
Башымны җиргә ора.
Өзгәләнәм, сызланамын, —
Гомерләр үтә тора.

Баш өстендә күк күкри,
Камчылый яшеннәре.
Сабырлыгымны җыеп мин,
Күз яшен яшерәмен.

## МИҢА ТАНСЫК

Кар сулары челтер-челтер ага,
Тау битенә карыйм: ачыла.
Күкләр аяз, болыт әсәре юк,
Караш төшә офык очына.

Миңа тансык ташу сулар шавы,
Җиргә шыткан яшел чирәме.
Урман-кырлар уяналар инде,
Тирәкләрем серен сөйләде.

Биләүләрдә агач бөреләре,
Сөеп кенә җилләр тирбәтә.
Яз кешегә сөю алып килә,
Кабул булды минем теләк тә.

Җирнең төсе, яме арта бара,
Кабатланып тора гомергә.
Назларыңнан мине мәхрүм итмә,
Югалтасы килми һичбер дә.

Илгә кайтты кошлар ерак яктан,
Күңел түрләренә юл алды.
Сагышларым, шәүлә булып кына,
Күз алдымнан китеп югалды.

## ИР-ЕГЕТЛӘР ЧЫГА ЮЛГА

Ир-егетләр баскан юл чатына,
Кая китсәләр дә ирекле.
Күрәчәген алар юллап чыккан,
Ирек куйган язмыш бу тиклем.

Җиде якка җиде юл сузылган,
Теләгәнен сайлап аласың.
Нинди табыш, нинди һәлакәткә
Очраштырмас адәм баласын.

Юллар төрле, берсе илтә данга,
Икенчесе аның афәтле.
Күк артына ыргытмаслар әле
Безгә тигән олы бәхетне.

Дәрәҗәгә-данга менәлмәдем,
Юл газабын гына күрсәттең.
Дусларыма хәтта сиздермәдем,
Юан башы төште күсәкнең.

Төрле кеше төрле юлда йөри,
Игелек кыла уңган, булганы.
Урлап-талап яшәүчеләр дә бар,
Явыз ният белән туганмы?

Юллар сүтә гомер йомгакларын,
Күңел күнә, йөрәк төшенә.
Айга-йолдызларга менеп йөрим,
Диңгез кичәм мин дә төшемдә.

## КАЗЛАР

Казлар йөри болын итәгендә,
Кыяк үлән ашап чемченә.
Төркем-төркем ак болытлар кебек,
Бер урында тормый, күченә.

Тәгәрәшеп үсә бәбкә казлар,
Җәйнең рәхәтенә тарыгач.
Кендекләре җиргә береккән күк,
Кунаклыйлар әллә арыгач.

Өметләнеп караш төшерәмен,
Күз алдымда тотам көзләрне.
Һәрбер йортта каз өмәсе узар,
Буй җиткергән күрше кызлары.

Сузып уйнар егетләре гармун,
Чыңлап китәр көмеш телләре.
Яхшылыкка юрыйм төш күрсәм дә,
Кабул булсын яшьләр теләге.
Татлы хыял — яшәү терәге.

### ВАКЫТ ҖИТКӘЧ

Вакыт җитсә, искән җил дә тына,
Шаулап килгән болыт тарала.
Мең хәрәкәт, мең үзгәреш күрәм
Күзне ачып йомган арада.

Вакыт җитсә, таудан ташлар ага,
Күкләр тетрәп яңгырлар ява.
Таң уяна хозурлыгы белән,
Үлән битләрендә чык яна.

Вакыт җитсә, күк кабагын ача,
Закон хөкеме дә үзенчә.
Гасыр буе килгән бу күренеш,
Күпләр кала һаман сизмичә.

Вакыт җитсә, көнне төн алмаша,
Чолгап ала кара пәрдәсе.
Азмы дөнья алдый кешеләрне,
Яшәүнең соң нинди мәгънәсе?

Вакыт җиткәч, кеше акылы белән
Ерак галәмнәргә юл сала.
Мин ышанып җирдә яшим әле:
Могҗизалар туар, иншалла.

## ЫЖГЫР БУРАННАР

Йомшак мендәрләргә ятсам да тик,
Керфегемә йокы кунмады.
Күкләр, җирләр бергә томалана,
Тышта дулый кышның бураны.

Кайнар тыным белән бозын эретеп,
Тәрәзәмә үрелеп карадым.
Ыжгыр җилләр ишегемне кага —
Нинди хәлгә, дөнья, тарыдың?

Ак гарасат кар таулары өя,
Шәрә агач тора калтырап.
Юлда кайталмаган кешеләр бар,
Урынымнан торам аптырап.

Идән буйлап ишек-түрле йөрим,
Җил сызгырып керә ызбага.
Авыр уйлар башка килеп төште,
Борчылдыра йөрәк, сызлана.

Ак томанга төреп күк йөзләрен,
Кургаш итеп сибә карларын.
И, табигать, сабырлыгың кая,
Әллә шулай җирне каргадың?..

* * *

Төрле хәлләр туып тора,
Җир тетрәп, су баса.
Кеше бәлагә тарымас,
Хәвеф-хәтәр булмаса.

Ае-кояшы тотыла,
Күктә йолдыз атыла.
Бер йөрисе килә менеп
Җиденче күк катына.

Йә җирләр корып ярыла,
Йә коя яңгырлары.
Яшеннәр яшьнәп атыла,
Күкрәүләр яңгырады.

Ахрызаман җитә диеп,
Картлар сөйли — хаклымы?
Көйсезләнә кызлар сыман —
Табигатьнең холкымы?

Җирнең әле бер почмагын,
Әле икенче төшен
Тетрәндерә, сискәндерә,
Табигать, синең көчең.

## ТАБИГАТЬ ХӨКЕМЕ

Бермәл тына искән җиле,
Эри яуган карлары.
Табигатьтә күп үзгәреш,
Кискен хөкем карары.

Тукталып тормый аз гына,
Су кебек еллар ага.
Мәңгелек түгелдер йөрәк,
Күкрәктә ярсып кага.

Күз яуларын алган бизәк
Җуела, төсе уңа.
Кайгырмыйча, шикләнмичә,
Күнеп яшимен шуңа.

Ташпулатлы зур калалар,
Тигезләнгән җир белән.
Хәрабә хәленә калып,
Туфрак булганын беләм.

Үткәннәргә кул болгадым,
Колак саламын дәшми.
Дөньяга килгән бар кеше
Вакытлы гына яши.

## АГЫМСУ

Уймак-уймак булып җитез ага,
Ярларына елга сыймады.
Әйлән-бәйлән килгән кызлармыни,
Ак күбекләр суда уйнады.

Йөгәннәрен салган тулпар, дисең,
Агымсулар ярсып чыңлады.
Елга ярларында боргалана,
Зәңгәр йомгагына чорнады.

Бер дә тынып калган сәгате юк,
Кай якларга болай ашыга?
Еллар-айлар ага гел туктаусыз,
Чыга алмый юллар очына.

Тугайлары тулган көмеш моңга,
Ак дулкыннар ярда уйнады.
Иелгән баш күтәрелсен әле —
Агымсуга салам уйларны.

## КҮЗЛӘРЕМДӘ КАЛДЫ НУРЫ

Тәрәзәмә төште шәфәкъ нуры,
Учак уты төсле тоела.
Урам читендәге тупылларның
Яфраклары җилгә коела.

Иртән төшә салкын кыраулары,
Моңсуланып гөлләр карады.
Ел фасылы гел дә үзгәрүчән,
Сагыш шәлен иңгә урады.

Кая очкан кошлар тугайлардан,
Өн-аваз юк, тәмам югалган.
Туасы көн куанычлы булсын,
Өметләнеп шуңа юанам.

Көз мизгеле мине уйландыра,
Бертуктамый салкын җил исте.
Тирә-юньгә ак пәрдәләр ябып,
Йокыларга тарыр җир өсте.

Күнәрсең бит, йөрәк, сизенәмен,
Борчылдыра мине бу кичем.
Сары нурлар чәчеп шәфәкъ сүнде,
Күзләремдә калды, көз, төсең...

## ГӨРЛӘВЕКЛӘР ЧЫҢЛЫЙ

Көмеш кыңгыраулар сыман,
Гөрләвекләр чылтырый.
Ак мәрҗәннәр төсле булып,
Кар өсләре ялтырый.

Кояш казанына салып,
Кайнатамы карларны.
Расланган мәңгелеккә
Язның хөкем-карары.

Сукмагын, юлларын таба —
Йөгерә гөрләвекләр.
Күгәрчен түше диярсең,
Җемелди күлләвекләр.

Челтер-челтер килеп ага
Бертуктамый кич-иртән.
Колакка керде тавышы —
Кар суларын ишетәм.

* * *

Күл читендәге көймәләр
Су өстендә тибрәлә.
Каңгылдаша каз-үрдәкләр, —
Күз карашым төбәлә.

Дулкыннар кага ярларын,
Чайкады көймәләрне.
Күктәге кошлар төркеме
Күл буен тирәләде.

Көймәләр ярсу тулпар күк,
Бәйдә тора тезгенле.
Таңны шәфәкъка ялгаган
Җәйнең ямьле мизгеле.

Акчарлаклар булыр идем —
Очарга ничек итеп?
Дулкыннар ярам көймәдә,
Тирбәләм бишек итеп.

## СУСАГАН СӘХРӘ-КЫРЛАР

Күкрәп килде күк өстеннән болыт,
Сусап калган сәхрә-кырларым.
Басуларда уйный яшел дулкын,
Уҗымнарга җәлләп карадым.

Җир ярыла, иген сары көя,
Тынны кура бөркү һавасы.
Җиләс җил дә исми аз гына да,
Хафалана адәм баласы.

Килгән болыт таралып та бетте,
Җиргә төшми яңгыр бөртеге.
Игенченең изге максаты да,
Уй-фикерләре дә бертөрле.

Өметләрнең өзгәләнгән чагы,
Теләкләрме әллә соңлады?
Күк йөзенә карашларын төбәп,
Авыл халкы яңгыр сорады.

## ТУГАЙЛАР БУЙЛАП ЙӨРДЕМ

Кунак көткән йорт шикелле тугай,
Хуш ис бөрки асыл гөлләре.
Тирә-юньгә җыр авазы сала,
Сандугачның моңлы телләре.

Яшь тирәкләр күкрәү көтә күктән,
Күз карашым, ерак йөгерден.
Йомшак үләннәрен келәм итеп,
Тын сукмаклар буйлап йөр(е)дем.

Хисләремә дәрт-куәтен бирә
Яфрак шавы, тибри алкышлар.
Җыйнаулашып бергә мәҗлес ясый,
Концерт бирә монда бар кошлар.

Мин бушанып калам уйларымнан,
Куанычлы яшәү көче бар.
Бөдрә таллар купшылыгын күрдем,
Һәр чәчкәнең үзгә төсе бар.

Иямәндем, юанычлар таптым,
Кагылмады җилең-давылың.
Тугайларга килгәч мин кичердем
Яшьлек көннәремнең дәвамын.

## ХӘТЕРДӘ УЗГАН ЕЛЛАРЫМ

Хәтердә узган елларым,
Сагынып искә алам.
Күргән төш шикелле генә,
Уйларда торып калам.

Вакыт чорный йомгагына,
Айны, елны, көннәрне.
Алып китәр мәңгелеккә
Бу дөньядан кемнәрне.

Күз нурларым сүрелмәсен,
Күкләргә тиңлим төсен.
Ашкынып тормый йөрәгем,
Бетеп барамы көчем?

Биек таулар чүгеп кала,
Эри төннең карасы.
Гомер агышы туктамый,
Тоташ еллар арасы.

Вакыт чикләрен чыгалмыйм,
Бер генә сикерәсе.
Сагышым булып каласың,
Яшьлегем хатирәсе.

## СИҢА ТАБЫНДЫМ

Мин арыдым, көче калмый кулның,
Йокы тапмый төндә сызланам.
И, чибәр кыз, сиңа бар да кызык,
Яшьлек күкрәүләрең узмаган.

Салкын җилләр сиңа кагылмаган,
Тормыш йөген сиңа салмаган.
Күпне күреп, нужа кичердем мин,
Кара чәчләрем дә чалланган.

Синең күзләр нурлар чәчеп балкый,
Иңнәреңдә чәчең толымы.
Мин, ир заты, сизмичә дә калдым,
Күңелләрем сиңа табынды.

## ЮЛЛАРЫБЫЗ ОЧРАШТЫРМАС

Юлларыбыз башка очраштырмас,
Аерылды төрле якларга.
Син сереңне башкаларга чиштең,
Минем караш төште ятларга.

Намус кушып, хөкем чыгарганда,
Газапларны йөрәк яңарта.
Эндәшмәбез, ләм-мим сүз әйтмәбез,
Тәкъдир сукса безнең яңакка.

Гафу үтенергә каламы соң,
Бу тормышны җиңел уйладык.
Тез чүктерде кайгыларын биреп,
Язмыш белән, ахры, уйнадык.

Башларыңа карлар, бозлар яуды,
Мин адаштым кереп күзләргә.
Яшәвемне раслап күп мәртәбә,
Ихтыяр-көч таптым түзәргә.

Онытырга теләп ерак киттем,
Тансык түгел барыр юл кемгә.
Яфракларын койган агач сыман,
Тыныч кына карыйм бу көнгә.

## БОРЧЫЛМА ҮТКӘНЕҢӘ

Керфегеңә кунган яшь бөртеге
Яңа елның якты кичендә.
Борчылдыңмы үткән көннәреңә,
Исәп тоттың барсы өчен дә?

Күңел сыкрауларын оныт әле,
Шатлыкларың калсын үзеңдә.
Күктә янган йолдыз сыман балкы,
Елмаюың чыксын йөзеңә.

Яуган карлар эри, сулар кибә,
Җиргә килгән бер китми калмый.
Кичерешләр, беләм, төрле була,
Йөрәк кенә барын аңламый.

Күз яшеңне яшер, күрсәтмәле,
Булган ышанычны җуймаек.
Яңа елның ямьле табынында
Һәммәбезгә бәхет юллаек.

## ҮЗ ЮЛЫМНАН КИЛӘМ

Үзем генә белгән юлларым бар —
Малай чакка кайтып урадым.
Төшләнгәнмен бары, иртән торгач,
Куанычлы хәлгә юрадым.

Таныш сукмакларда озак йөрим,
Зәңгәр офык ача капкасын.
Юксынуым, сагышларым белән
Яшьлегемә килә кайтасым.

Еллар шавы колагымда калды,
Үткәннәргә карый күзләрем.
Җаным кыраулардан өшер инде —
Каршы алды моңсу көзләрем.

Дөнья хөкеменә, канунына
Яши-яши барыбер күнәмен.
Гомер юлы буйлап яшьлегемнән
Киләчәкне юллап киләмен.

## ОЗАТЫП КАЛАМ

Мин озатам һәркөнемне
Югалту, табыш белән.
Кайгы-хәсрәт, шатлыгымны
Ике өлешкә бүләм.

Озатулар була моңсу,
Йөрәк моңа күнмәде.
Югалтусыз булса икән:
Уйлыйм килер көннәрне.

Күктә йөзгән болытны да
Өнсез каламын карап.
Төрле була кичерешләр,
Хәтердә тотам барлап.

Аккан суны, искән җилне
Карап калам озатып.
Их, кадерле минутларны
Булса әгәр озайтып.

Юлга озатам дусларны,
Иминлек, уңыш теләп.
Тормыш түренә үрләргә
Ышаныч, теләк кирәк.



## ӘНИГӘ ХАТ

Синоптиклар алдан хәбәр итә:
Җилләр дулап, буран котыра.
Күзне ачып булмый, йөзгә сибә,
Урамнарга карлар тутыра.

Кар пәрдәсе төреп алган тәмам,
Ак болытлар күкне каплады.
Вокзалларда тулы халык гөрли,
Машиналар йөрми, туктады.

Эшем бетми, җаным тынып тормый,
Мин җыендым юлга күптән үк.
Авылдашлар ничек яши икән,
Туган якка озак кайткан юк.

Кар туздырып гарасатлар уйный,
Сукмак бетеп, арам өзелде.
Күк бозларын эретеп тыным белән,
Тәрәзәмнән алмыйм күземне.

Бу юлы да кайталмыймын, әни,
Хатлар язам сиңа буранда.
Өзелеп юксындыра, күңел моңсу,
Көннәр йончу тора Уралда.

* * *

Йорт сала күпләр бүген
Агачтан, таштан өеп,
Икешәр-өчәр катлы,
Күккә үрелгән биек.

Законы-хөкеме дә
Үзгәрде, хәзер башка.
Ил, халык җилкәсендә
Йортлар төзиләр бушка.

Капкасы да тимердән,
Җил дә керәлми үтеп.
Миңа да бәхет кошы
Кунмасмы, яшим көтеп.

Кемгә алтын йомырка
Сала көн дә тавыгы.
Берәүгә — җирдә оҗмах,
Берәүгә — җир тәмугы.

## ГОМЕР ЮЛЫ ТӨРЛЕ

Гаҗәп дөнья: һич тә хисаплашмый,
Кемнедер ул итә солтаны.
Дан-дәрәҗә, тәхет, бәхет бирә,
Канат кага күктә шоңкары.

Кемдер берәү яңа шытып чыккан,
Иренендә сөте кипмәгән. —
Олы хөрмәт аңа баглыйлар,
Ата-бабасы да көтмәгән.

Кемдер берәү гаделлекне юллый,
Ишетепме, әллә белепме.
Зинданында яткан тоткын кеше
Төштә күрә бары ирекне.

Кемдер берәү максатына җитми,
Өмет-ышанычын югалта.
Әзмәвердәй ирне баш идереп,
Тал чыбыктай бөгеп елата.

Кемдер соңгы минутларын көтә —
Гомер озынлыгы төрлечә.
Кем соң кыла алган каһарманлык,
Авырлыклар бер дә күрмичә?

* * *

Кышка керсәм, бар аклыгын аның
Бүләк итәр идем тик сиңа.
Аклык, сафлык һәрчак юлдаш булсын,
Гашыйкларча карыйм мин шуңа.

Язлар җитсә, сиңа назын юллыйм,
Сандугачлар сайрап юатсын.
Йөрәгеңдә йөрткән сагышларны
Керле күлмәк итеп юарсың.

Җәйгә чыксам, кочагыма җыеп,
Тугай чәчәкләрен бирермен.
Күзләрең күк зәңгәрләрен сайлап,
Такыялар аннан үрермен.

Көзләр җитсә, бөтен йомартлыгын,
Хозурлыгын күреп хушланам.
Без яшәгән җирнең гүзәллеге,
Матурлыгы төрле — ышанам.

## МӘҢГЕЛЕК МОҢ

Зәңгәр диңгез сыман, урман шаулый,
Дулап ярсу дулкын күтәрә.
Колач җәеп офык читләренә,
Башын сузып карый күкләргә.

Урман мәңге моң эчендә яши,
Сайрар кошлар бала үстерә.
Өермәләр белән яшен уйнап,
Болыт килгән аның өстенә.

Елның бөтен фасылы да шулай,
Куеп киткән һәрчак үз төсен.
Бәрәкәтле җирдә үстергәнсең
Татлы җимешләрнең төрлесен.

Күпме җан иясе урын тапкан,
Өн ясаган, корган оясын.
Серен ачмый, ямен саклый белә,
Сукмагында йөргәч, тоясың.

Сискәнәсең кайчак, юкка түгел,
Явар яңгырлары кичеккән.
Гасырлардан килә мәңгелек моң,
Урман өн-авазын ишетәм.

## МИН СӨЕНӘМ

Мин сөенәм, авылымда
Туй узса, килен төшсә.
Бал кортлары ширбәт җыйса,
Бакчамда чия пешсә.

Мин сөенәм, авылдашлар
Бурап яңа йорт салса.
Җырын көйләп, чишмәләрем
Колагымда чыңласа.

Мин сөенәм, авылымда
Картлар сәламен алсам,
Игелек кылсам кешегә,
Дәртләнеп җиргә басам.

Мин сөенәм, авылымда
Дөньяга бала туса.
Куанычым кырга сыймый,
Басуда иген уңса.

Мин сөенәм, авылымда
Кошлар корса оясын.
Тормыш мәңге дәвам итәр,
Якты өмет уянсын,
Күңел шомы югалсын.

## БЕЗНЕҢ ХАЛЫК

Безнең халык кайчан шат яшәгән,
Рәхим-шәфкать кем соң күрсәтте?
Патшасы да, түрәсе дә аның
Баш өстендә тоткан күсәкне.

Гаделсезлек илдә бетмәгәчтен,
Богау кыса аяк-кулларны.
Гомер буе җәбер күргән халык,
Кимсетелде, әзме кыйналды?

Безнең халык чыдам: өнсез калган,
Бар галәмгә чаң да какмады.
Олы җанлы, уңган, горур да ул,
Мирас итеп барын саклады.

Безнең халык кайчан ирек яулар:
Көн күрсәтми кемнәр, юл бирми?
Күп гасырлар моңа шаһит булдык,
Күңел бозларыбыз эреми.

Безнең халык үгисетелүнең
Сәбәпләрен кайдан эзләргә?
Тарих язар әле төпле сүзен,
Тешне кысып нигә түзәргә,
Богауларын кирәк өзәргә.

## КАЕН ҮССЕН

Каберемдә ап-ак каен үссен,
Булсын минем якын сердәшем.
Баш очымда басып, анам кебек,
Хәлең ничек, диеп эндәшсен.

Бөтен гөнаһларым ачыкланыр,
Гүрем кысып, шулчак өшетер.
Кабер өстендәге каен гына
Авыр газабымны ишетер.

Тынлык, караңгылык сискәндерер,
Шәм итәрмен каен яктысын.
Туфрак күмәр, җансыз гәүдәм тынып,
Өнсез генә беләм ятасын.

Дус-ишләр дә, якын туган да юк,
Кем куяр соң чәчкә кабергә?
Каен сеңлем, сиңа табынырмын,
Җыр-моңнарың белән кадерлә.

Мәңгелек йорт ишек-тәрәзәсез,
Аннан чыккан кеше юк әле.
Күбәләктәй җаным, каен, сине
Эзләп очар өскә югары.

## ДӨНЬЯ ЯКТЫСЫ

Гомер юлын кичкән кеше
Күп төрлегә төрләнә.
Өскә кигән күлмәкләр дә,
Күңелләр дә керләнә.

Тормыш ачысын тоямын,
Күрәм кайгы карасын.
Үлчәүләргә салып булмый,
Йөрәкнең бар ярасын.

Юллар озын, адаштыра,
Уйлар диңгезе тирән.
Бер сер булып калсын әле, —
Башны имәдем түбән.

Җил-давыллар кага-суга,
Аяктан кайчак ега.
Бер ходайга ялварырмын,
Укырга беләм дога.

Хәвефле хәлләрдә читен —
Җанны да яклыйсы бар.
Рәхмәте зур кешеләргә —
Дөньяның яктысы бар.

## ГОМЕР БЕР ГЕНӘ

Чәчләремә ак кыраулар төште,
Тирән сырлар ятты йөземә.
Төрле дәва эзләп карасам да,
Хәлсезләнде йөрәк — сизелә.

Күзгә чәчкәләр күк суламы соң,
Минем кояш төшкән шәфәкъка.
Читтән генә күзләп әҗәл йөри,
Җан сискәнеп куя шулчакта.

Акчага да сатып алалмыйсың,
Кешә гомерләре бер генә.
Күз иярми, аргамаклар кебек,
Ел артыннан еллар йөгерә.

Ни күрсәм дә, бик яшисе килә,
Хушландыра айлы кичләрем.
Авырсам да, сызлансам да үзем,
Йөз яшәргә әле исәбем...

## ТУГАН ҖИРЕҢ ЮКСЫНА

*Ә. Атнабаев истәлегенә багышлап*

Синең, шагыйрь, авылыңа бардым,
Урамыннан кат-кат урадым.
Зур юксыну хисе сызландыра,
Йорт-нигезең кереп карадым.

Ятим калган йортың моңсуланып,
Шаһит булдым күреп мин моңа.
Әйтерсең лә, бөтен авыл халкы
Сусап калган сыман җыр-моңга.

Әнгам, дус та, каләмдәш тә идең,
Бергә сүттек гомер сукмагын.
Хәтерлимен ораторлар кебек
Шигырь укып йөргән чакларың.

Ходай кешесенә белеп бирә
Буй-сынын да, сәләт тә, көч тә.
Көнчелләр күп хөсетлек кылса да,
Курка-өркә белмәдең һич тә.

Шәм шикелле янып яшәдең син,
Кызганмадың йөрәк җылыңны.
Туган җирең җирсүләре чиксез,
Чишмәләре көйли җырыңны...

## ХАКЛЫК ӨЧЕН ҖАН АТАМ

Бар эшемне юкка чыгаралар,
Юк эшне дә кайчак мактыйлар.
Эт шикелле өзгәләрләр иде —
Бәйләнергә җаен тапмыйлар.

Максатыма ирешмичә калам,
Кызарталар кайчак битемне.
Җитез(е)рәк, биег(е)рәк үрли —
Ялагайлар сүзе үтемле.

Хаклык өчен җанны фида кылам,
Яшәү шарты ифрат катлаулы.
Дәрәҗәгә, данга кызганым юк,
Мин хезмәтем белән мактаулы.

## МИН ЫШАНАМ

Кар астыннан умырзая чыга,
Мин ышанам, өмет багамын.
Көткән көнне тизләтергә исәп —
Ишек-тәрәзәсен кагамын.

Баскан җирдән бәреп чишмә чыга,
Чакматаштан чәчрәп ут яна.
Мин ышанам: шәрә тауларны да
Яшел хәтфә үләннәр яба.

Бер адашып йөргән мосафир күк,
Эзсез узса моңсу көннәрем,
Эх, менәсем, бик беләсем килә —
Теге ягын айның күрмәдем.

Күк өстендә яңа йолдыз балкыр,
Якты хисләр ташып бөркелер.
Сүнгән өметләрне тергезерлек,
Бер ышаныч күңелгә килер.

Күргән төшем чынга аша бара,
Мин күптәннән моңа ышанам.
Могҗизалар туган бу заманда
Җиденче кат күккә очалам.

## КУЛЫМДА БУЛА КИТАП

Пушкин, Тукай китапларын
Тезеп куям киштәмә.
Үзем белән алып китәм,
Кайда сәфәр китсәм дә.

Китапларны юлдаш итәм,
Сердәш була серемә.
Упкынынннан алып чыга
Бу тормышның үренә.

Якын дус та, киңәшче дә,
Илһам бирә, көч бирә.
Укыган кеше тиз аңлый,
Олы шатлык кичерә.

Талпындыра, канат куя,
Күңелсез күңелләнә.
Дәртләндерә, хушландыра,
Өметләр бөреләнә.

Нинди изге җаннар булган,
Алар хакында уйлыйм.
Иртән дә, кичен дә укыйм:
Кулымнан китап куймыйм.

* * *

Хөрмәт итәм — данга лаек була,
Олылыймын хезмәт кешесен.
Җанны, канны һич тә кызганмадым,
Мин туганмын, беләм, эш өчен.

Бервакыт та каушап калганым юк,
Авырлык бар диеп юлымда.
Ару белми, өмет белән яшим,
Бар уйларым — хезмәт турында.

Ышанычым гел акланса икән,
Күтеп алам хезмәт иртәсен.
Мин тормышка ямь өстәргә тудым,
Гүзәллеге җирнең күп тә соң.

Хезмәт дәрте белән яшәгәчтен,
Күкрәк ачам хәтәр җилләргә.
Гөлләр шыта, шаулап иген үсә
Кайнар тирем тамган җирләрдә.

## АВЫР ХӘЛГӘ КАЛГАНСЫҢ

*Каләмдәш дуска багышлыйм*

Ничә көннәр шагыйрь айный алмый,
Көнне төннән тормый аерып.
Хәлсезләнеп, яралы кош кебек,
Түшәгендә ята авырып.

Өстәлендә тора буш шешәсе,
Балык башы, икмәк кисәге.
Сигар төпчекләре, тузган көлләр,
Шаулы узган аның кичләре.

Башы чатнап, калтырана кулы,
Томанлана бөтен күз алды.
Хәмер шаукымында газаплана,
Нервылары чәнчеп кузгалды.

Күпләр килә шагыйрь йортын белеп,
Күңел ача, мактый дошманы.
Мөшкел чакта хәлен килеп белде,
Тәнкыйтьләде аны дуслары.

Шагыйрь тормышында алкышлаулар,
Тост әйтүләр була, хак та соң.
Ул хәерсез кабатлап торгач,
Танымагач шуның хатасын,
Авыр хәлгә калып ятасың.

## ХАТЫННАР

Оят та юк, әдәп качты тәмам, —
Мин әйтәләм: моңа хакым бар.
Күпме кирәк, шулай типтерәләр,
Бу заманда азды хатыннар.

Эчкән, тартканы да бик күбәйде,
Бар тормышның ямен югалта.
Кәнтәйләрне ничек яңакларга, —
Нәфсе аздырырга ярата.

Ир белән дә юньләп тормый алар,
Азып-тузып йөргән ил тулы.
Җирдә арта ятим туган бала,
Кем кызыдыр, белмим, кем улы?

Нигә шулай ямьсез кылананалар,
Бу хатыннар кемне алдыйлар?
Кәеф сата, шөһрәт өчен яши,
Дөньяда күп хәзер андыйлар.

Алар өчен тормыш сабантуе,
Бәйрәмнәргә бәйрәм тоташа.
Ирләр шөрләтерлек ят холыклы
Хатыннардан куркам — кот оча.

## ОЛЫ ЮЛГА ЧЫГАМ

Тар сукмактан киләм олы юлга,
Көтеп тора алда максатым.
Ерак сәфәр кылган үземне бер
Ялгыз юлаучыга охшаттым.

Киртәләр күп очрый юлларымда,
Сүтеп барам, барын җимерәм.
Зәңгәр офыкларым яулык болгый,
Артка чикмим баскан җиремнән.

Миңа каршы хәтәр җилләр исә,
Аягымнан гына екмасын.
Ышанычым яшәү дәрте бирә,
Афәтеннән ходай сакласын.

Кояшны да чыгармаслар иде,
Күпләр минем белән булышты.
Курыкмадым, өрекмәдем һич тә —
Җыйнаулашып ятлар юл басты.

Аякларым тала, алга атлыйм,
Тирәнәя сулыш һаман да.
Мин төшендем: теләкләргә ирешү
Җиңел түгел безнең заманда.

* * *

Без дә казлар саклап үстек,
Атлар да йөгәнләдек,
Угрылыкта, яман юлда
Йөрергә өйрәнмәдек.

Без дә яшь чакта йөгердек,
Бар җиргә дә өлгердек.
Бөркет кунган кыяларга
Буй җитмәде — үрелдек.

Телем генә икмәкне дә
Без бергәләп бүлештек.
Замана көйсез булса да,
Елмаештык, көлештек.

Без дә усаллыкны күреп,
Якалаштык, алыштык.
Төрле чакларыбыз булды,
Дөнья белән таныштык.

Сәхрә-кырларга сокландык,
Җанга рәхәт табарлык.
Буйга үсеп җиткәч кенә
Төрле якка таралдык.

## ПОЕЗДЛАРНЫ ЮЛГА ОЗАТАМ

Поезд чаба, вагоннары зыңлап,
Тәгәрмәчләр җырын көйләде.
Моңсу чакта мин дә китәр идем, —
Әллә ничек җае килмәде.

Газиз башны берәр якка илтим,
Борчу-мәшәкатьне калдырып.
Авыр кичерешләр белән яшим,
Йөрәк утларымны яндырып.

Җир тетрәп калтырана сыман, —
Гаделсезлек җанны өттерде.
Яңа көнгә күзләремне ачтым,
Кайнар яшьләремне түктерде.

Офыкларга караш тартылганда,
Поездларны юлга озатам,
Моң-сагышларымны алып китсен,
Өнсез булып торам азактан.

Гайбәтчеләр тынар, этләр өрмәс,
Китәм әле мин дә еракка,
Куанычлар, юанычлар юллыйм,
Бер тынгылык эзлим йөрәккә.

## ХӘТЕР КАПЧЫГЫМ ТУЛЫ

Берәм-берәм хәтер капчыгымны
Ефәк тасма белән бәйләдем.
Табышым бар, югалтулар да күп, —
И, язмышым, зур ла бүләгең.

Каз бәбкәсен саклап йөргән чаклар,
Буразналар ярган атларым.
Хәтер капчыгымда тулып ята
Тәүге тапкыр язган хатларым.

Гармун тартып узды яшьлегем дә,
Хисләр ташып торды ул чакта.
Хәзер искә алам, сагынамын,
Юксындыра сүнгән учак та.

Үткән еллар, айлар, көннәр, төннәр,
Корыч чылбыр булып тоташкан.
Дуслар, ятлар, шатлык, кичерешләр,
Соңгы чиктә бергә катнашкан.

Моңга чумган көзге урман төсле,
Күңелләрем моңсу — уйланам.
Гамьсез узган көннәрем дә булган —
Шуларына инде оялам.



4 — 676

## КҮҢЕЛ КОШЛАРЫМ

Күңел кошларымны очырамын,
Чыгарамын барын читлектән.
Җил-давыллар килеп кагылса да,
Канатлары үсеп җитлеккән.

Галәм түрләренә очып менсен,
Диңгез дулкынында тирбәлсен.
Нәҗәгайлар сыман уйнаганда,
Җитезлеген килә күрәсем.

Күңел кошларыма ишек ачам,
Илләр гизсен, чыксын иреккә.
Нинди язмыш алда сагалыйдыр:
Күзаллап та булмый, күреп тә.

Тоткынлыкта җәберләнмәсеннәр,
Хөр яшәсен күреп үз көнен.
Богауларга, хөкем кылырга да
Хакы юк ич җирдә беркемнең.

Күңел кошларыма җимнәр сибәм,
Татлы ризыкларны ашатам.
Күктә горур, җирдә кыю булыр
Бөркет баласына охшатам.

## КУРКУ БЕЛМӘДЕМ

Дәрья суларында йөздем,
Карурманын да кичтем.
Тау кыяларына мендем,
Тирән упкынга төштем.

Әнинең яраткан улы,
Газиз баласы идем.
Тормыш йөкләрен сөйрәдем,
Яшьли камытын кидем.

Ни күрсәм дә ачынмадым,
Ятларга сер бирмәдем.
Өермәләр уртасында,
Җанда курку белмәдем.

Зарланмадым, хурланмадым,
Горурлык хисе сүнми.
Булдыксыз, гамьсез итеп гел,
Кемнәр соң мине сөйли?

Юлларда очрап торалар
Җил-давылы, кары да.
Дошманнар күп, дус-иш тә бар —
Ходай биргән барын да.

## ҖАННЫ ӨШЕТТЕҢ

Җәйләрнең дә ямен алып киттең,
Җылы тапмыйм, җанны өшеттең,
Аерылуга, югалтуга чара
Табалмадым, ахры, кичектем.

Төнге йокымнан да мәхрүм иттең,
Керфек очларында күз яшем.
Җир тетри, күк чайкала сыман,
Авыр уйлар белән мин яшим.

Аерыла да, кавыша да кеше,
И, йөрәгем, ничек күнәрсең?
Биргән вәгъдәләрең җилгә очты,
Язмышымдыр, ахры, күрәсең.

Пар аккошлар күлгә төшкән чакта,
Күзләремне карыйм талдырып.
Ни аяныч: сөйгән кешем мине
Ташлап китте ялгыз калдырып.

Тормыш юлларымы адаштырды,
Ачыклыймын хәзер сәбәбен.
Бер күрәсе килгән чакларым бар,
Җилләр әйтер сагыну сәламен.

## АВЫЛ УРАМНАРЫ

Без үскәндә җанлы, ямьле иде,
Гөрләп торды авыл урамы.
Яшьләр бергә чыгып кич йөрергә,
Гармун уйнап, урам урады.

Су юлыннан кызлар кайта иде,
Пар чиләкләр асып иңенә.
Хатирәләр бик еракта калган,
Әллә төштә, әллә өнемдә.

Урамнарда карт тупыллар шаулый,
Җил тирбәтә кошлар оясын.
Өнсез калып ятим йортлар тора —
Хуҗалары аның кая соң?

Туй атлары үтми урам иңләп,
Кыңгырау тавышлары югалган.
Ялгыз калган картлар кебек, никтер
Авыл урамнары моңайган.

## КҮКРИ ЯШЬЛЕК ҖЫРЫБЫЗ

Вакыт агышы юмады
Йөрәктәге ярамны.
Кайтавазлар булып кайтты, —
Хатирәләр яңарды.

Әйтерсең болытлар шаулый,
Ташулар ярга какты.
Күңелнең бер почмагында
Ал таңнар булып атты.

Шиңгән гөлләрне терелтә,
Сүнгән хисләр җанлана.
Давыллы кичерешләрем,
Кызык, шаулы замана.

Таныш моңнар урап кайтты,
Күп еллар аша исән.
Бу җыр дәртле, хата булмас,
Җаныма якын, дисәм.

Күкрәп күңелем күгендә,
Яшеннәр кебек яшьнәр.
Безнең яшьлек җырыбыз бу,
Онтылмас, мәңге яшәр.

## ҮЗ ҖИРЕМДӘ

Мин килмешәк түгел үз җиремдә,
Суын эчәм, ашыйм икмәген.
Ата-бабам гомер кичкән төбәк,
Йөрәк аңлый газиз икәнен.

Гөл үстерәм, иген чәчәм кырга,
Тормышыма ямьнәр өстәлә.
Нигъмәтем күп, татлы ризыгым мул,
Сый-хөрмәтем тулы өстәлдә.

Ияләндем яшәү канунына,
Хезмәт җимешемә сөенәм.
Өермәләр купкан хәтәр чакта,
Үз җиремә ятып сыенам.

Ояларын ташлап кошлар китә,
Мин күрмәгән ерак якларга.
Туган җирдән башка ямь табалмам,
Күзем кызып бармый юк-барга.

Йорт-нигезем имин-исән булсын,
Гомер чишмәм чыңлый, тынмасын.
Чит якларга китсәм сагынырмын,
Язмыш җиле читкә кумасын.

## ҖИРДӘ ЯШӘР ХАКЫМ БАР

Болыт булып килде кайгыларым,
Баш өстендә яшен яшьнәттең.
Һәрчак, тормыш, үгисеттең мине,
Җәбер күрсәтеп гел яшәттең.

Өстәлеп лә тора кайгы-хәсрәт —
Күз яшьләрем белән түләдем.
Ходай бирсен сабырлыклар гына, —
Ихлас күңелемнән теләдем.

Авызыма капкан ризык бармый,
Йоклыйм дисәм, тапмыйм йокымны.
Төнгә керсәм, шомландырып мине,
Күктә йөзгән аем тотылды.

Юл йөрергә чыксам адаштыра,
Аералмадым кыйбла ягын да.
Мин мосафир кебек күпне күрдем,
Карасын да, дөнья агын да.

Аягыма басам бар көчемә,
Юк сүрелмәс, миндә ялкын бар.
Гомер сукмагында ни күрсәм дә,
Җирдә яшәр өчен хакым бар.

## МӘКЕРЛЕ КЕШЕ

Уй-теләккә һәрчак каршы килде,
Максатыма калдым җитәлми.
Соравыма җавап бирми түрәм:
Тамак кыра, аннан ютәлли.

Эт шикелле койрык болгамадым,
Мин ялагай түгел, куштан да.
Юк, йомышчы малай була алмам,
Биеп тормам синең кушканга.

Мәкер белән юлга киртә салдың,
Әзерлисең тирән упкын да.
Мин иреклe, хөр йөрәкле кеше,
Сиңа булмам кол да, тоткын да.

## ГАРМУНЫМ КУЛЛАРЫМДА

Гармун дустым, синең белән
Яшь чакта ук таныштым.
Дәртле, моңлы, җырлы иттең
Гомеремнең агышын.

Икәү бергә бик күп йөрдек
Мәҗлесләрдә, туйларда.
Гармун моңына көнләшә
Сандугач та, тургай да.

Йөрәк серемне сөйләтәм
Гармуным телләреннән.
Исән-имин алып чыга
Ул хәсрәт күлләреннән.

Кайларга гына барсам да,
Кулымнан һич куймадым.
Урамнарда, сәхрәләрдә
Гармунымны уйнадым.

Күреген киереп тартам —
Киң алсын тыннарын да,
Җыр белән гомер кичерәм —
Гармуным кулларымда.

## ОЧРАШКАН ЮК

Табыннарга бергә җыелган юк,
Очрашмыйбыз хәзер бик күптән.
Ыгы-зыгы, вак мәшәкать белән,
И, гомерләр безнең күп үткән.

Җан җылысы җитми барыбер миңа,
Малайлар күк ихлас көлгән юк.
Төрле чаклар була бу тормышта,
Бер-беребезнең хәлен белгән юк.

Адашканда тойдым ялгызлыкны,
Егылгачтын сиздем көчсезлек.
Ни күрсәк тә һич тә зарланмадык,
Тау җимереп, ташлар күчердек.

Нәрсә булды, дуслар, белмим инде,
Очрашкан юк, сезне күргән юк.
Кайгы-хәсрәтләрне уртаклашып,
Серегезгә күптән кергән юк.

## ТӨННӘР БУЕ ЧИГҮ ЧИГӘСЕҢ

Әни,
Керфегеңә йокы кунган инде,
Төннәр буе чигү чигәсең.
Чекерәеп тонык ут каршында,
Күзләреңнең нурын түгәсең.

Кулың талган, ефәк җепләр сайлап,
Бертуктаусыз һаман кайныйсың.
Сагынуыңны беләм:
Күңел күзең аша
Үткән яшьлегеңә карыйсың...

## КЕШЕ

Кеше җирдә
Тормыш көтә.
Гомер юлын
Җайлап сүтә.

Эше белән,
Төсе белән,
Көче белән
Төрле, беләм.

Күңеле ак,
Карасы бар.
Җәрәхәтле,
Ярасы бар.

Бар моңлысы,
Бар җырлысы,
Бар шомлысы,
Бар җылысы.

Һәр кешенең —
Тик үз эше.
Үзгәлекле,
Кабатланмас —
Җирдә кеше.

## САБАН ТУЕ

Җиз кыңгырау тагып пар атларга,
Урамнарны яшьләр әйләнде.
Бабайлардан калган мирас безгә —
Сабан туе, хезмәт бәйрәме.

Яшь киленнәр сөлге нәкышләгән,
Кызлар яулык чиккән бәйрәмгә.
Хезмәт батырлары — ир-егетләр
Көчен сыный бүген мәйданда.

Олы табын җыела һәрбер йортта,
Өстәлләрдә — татлы сый-хөрмәт.
Кешеләргә бетмәс байлыкны да,
Шатлыгын да бирә тик хезмәт.

Бокалларга шәраб салыйк әле,
Бәллүр тавышлары чыңласын.
Хезмәт уңышларын без яулыйбыз,
Каршы алыйк тагын яңасын.

Зур тантана, шатлык кичерәбез,
Атлар уза болын буена.
Күңел ача, уйный, җырлый бүген,
Халык чыкты сабан туена.

## СОЛДАТ КАЙТТЫ

Ил хезмәтен үтәп солдат кайтты,
Озатканда бар да борчылдык.
Күрешкәндә йөзләр балкып китте,
Бала сыман телем ачылды.

Шәфәкъ алсулыгы сискәндерде,
Сизеп тордык ерак күкрәүне.
Сугыш афәтләре беткәне юк,
Уч төбендә җаным тетрәде.

Хәвеф-хәтәрләрдән сакланырлык
Чараларын күрик иң элек,
Солдатлар да кайтыр, күрешербез,
Бары булсын илдә иминлек.

## ЯЗГЫ ҖИЛ

Җилфер-җилфер, язгы җилкәй, истең,
Агачларның сөеп бөресен.
Күк сәламен әйтеп киттең миңа,
Илләр гизеп армый йөрисең.

Буразналар буйлап йөгереп уздың,
Канат какты басу түрендә.
Каеннарның чәч толымын сүттең,
Бар шөгылең миңа күренә.

Урамнарга ятып сызгырасың,
Дәрьяларда дулкын уяттың.
Яр башында таллар биеп тора —
Курайларны моңлы уйнаттың.

Язгы жилкәй, тәрәзәмне ачтың,
Челтәр пәрдәләрен күтәрдең.
Яшел үзәннәрнең җиләслеген,
Бөре исен миңа китердең.

## САНДУГАЧКАЙ

Сандугачкай кайтты бакчабызга,
Сагынгандыр, беләм, оясын.
И, кошкаем, тавышыңнан таныйм,
Туган җирдә шатлык тоясың.

Моң-авазың белән данлыйсыңмы,
Зурлыйсыңмы газиз йортыңны?
Ышанычың артты таныш җирдә,
Бөтен булган шигең онтылды.

Талпынасың күкләреңә менеп,
Яшел тирәгеңне сайлыйсың.
Йөрәк өзгеч, ах, моңнарың белән,
Бакчам уртасында сайрыйсың.

Өметләнәм: бозлар булып каткан
Сары сагышларым эресен.
Узган гомер, үткән юлларым да
Уйландыра мине төрлесен.

Моңнар дәрьясына төшеп йөздем,
Юанычлар таптым, күрәсең,
Заманалар авыр, хәтәр чакта
Хәл белергә миңа киләсең!

## КҮРЕШҮ КӨНЕН КӨТӘМ

Хушлашмадың, китеп бардың,
Миндә уйлар кузгатып.
Күзләремнән югалтканчы,
Карап калдым озатым,
Киттең уйлар кузгатып.

Син киткән якларда балкып,
Таңнар сызылып атты.
Җил шаяртып каеннарның
Яшел чугын таратты,
Миндә хисләр яңартты.

Сезнең яктан кошлар кайтты,
Тирәкләрдә кагына.
Юксынып яшимен хәзер,
Сагыш җанга кагыла,
Күңел сиңа табына.

Кабул итәм аткан таңны,
Кайнар сәламең итеп.
Өметләнеп мин яшимен,
Сөю язларын көтеп.
Гомерләр бара үтеп.

* * *

Гашыйк итте мине бер кыз,
Күзләре аның зәңгәр.
Йөрәгем нишләр, түзәрме,
Аңлашалмасак әгәр.

Татлы йокылар бүленә,
Аны күреп уянам.
Алай булса да сөенәм,
Төштә күреп юанам.

Бик күрәсем килә — нишлим,
Күңелемне басалмыйм.
Әйтер сүземне әйталмыйм,
Бар серемне ачалмыйм.

Җае чыгар әле, димен,
Ел артыннан ел үтә.
Кыз белән күңел һаман да
Аңлашу көнен көтә.

## МАЛАЙ ЧАКЛАР КАЙДА КАЛДЫ?

Кичә генә без малайлар идек.
Шау-гөр килеп бергә уйнадык.
Болын буйларына йөгереп чыктык,
Урам чатларында җыйналдык.

Ул чакларда дөнья кызык иде,
Чирәмнәргә ятып аунадык.
Йокылардан тордык егет булып,
Гомер узганлыгын аңладык.

Нинди юлда, нинди сукмакларда
Малай чагым калды адашып?
Еллар, айлар, көннәр, төннәр уза,
Бер-бер артлы тора алмашып.

Бергә үскән дуслар юксындырып,
Йөрәгемнән китми һаман да.
Бүген, үзем кебек, малаем да
Йөгереп, уйнап йөри урамда.

## СОҢЛАП КИЛӘ ЯЗЛАР ДА

Малай чакта күп талады
Әтәчләр, ата казлар.
Авылыма ямь китергән
Хәтердә һаман язлар.

Иләсләнеп йөргән чакта,
Юк-барга да көлгәнмен —
Җирнең гамен, матурлыгын,
Гүзәллеген күргәнмен.

Кызык күреп, мәзәк итеп,
Берни дә уйламадым.
Гаебем булса — таныдым,
Ачу да җыйнамадым.

Авыл урамын шаулаттык
Малайлар белән бергә.
Уйнап-көлеп гел ваемсыз,
Яшәп булмый гомергә.

Үзгәрә хәзер дөньясы —
Юаш ата казлар да.
Озак көттереп килә шул,
Соңга кала язлар да.

## ҖЫРЛАНМАГАН ӘЛЕ ҖЫРЛАРЫМ

Моң сарыды бөтен йөрәгемне,
Җырланмаган әле җырларым.
Офык артларында сагалый көк,
Чират көтә килер елларым.

Көзаллыйдыр атар таңнарым да,
Чакыра мине ерак юлларым.
Табышымны, куанычымны да
Яңа туган көннән юлладым.

Еллар санын, юллар озынлыгын,
Санап барам, тотам исәптә.
Гомеремнең үткән бар фасылын
Кичектерми, вакыт кисәтә.

Яңа көннәр ниләр алып килер,
Югалтумы, әллә табышмы.
Читләп узмый, бәгырьләрне телә
Ташкан хисләр, моңнар агышы.

Җырланмаган әле җырларым бар,
Йомгак итеп сүтәм юлларны.
Имин булсын, куанычлы булсын,
Көтеп яшим килер елларны.



# Җырлар

## БАЛА ЧАГЫМ ЧИШМӘЛӘРЕ

Сәхраләргә чыксам, тыңлыйм
Чишмәләрнең тавышын.
Күңелемдә урын алды
Яшь чактан ук таныш моң.

*Кушымта:*

Су юлыннан кызлар килә,
Чайкала чиләкләре.
Үзенә чакырып тора
Яшьлегем тирәкләре.

Гармун моңы, айлы кичләр,
Хәтердә бала чагым.
Камышлы күл, бөдрә таллар,
Чишмәле туган ягым.

*Кушымта* шул ук.

Туган ягым чишмәләре
Күңелләргә моң сала.
Җырларын көйләп йөримен,
Кайда гына барсам да.

*Кушымта* шул ук.

## ЯЗЛАР КӨТӘМ

Куанычлар, юанычлар эзлим,
Күз яуларын алган назлар бар.
Очрашырбыз әле,
Очрашырбыз,
Киләчәктән көткән язлар бар.

Еракларга юллар чакырып тора,
Сабырланмый җаным, нишләде?
Сагындырдың мине,
Сагындырдың,
Ашкындыра кайнар хисләрем.

Өметләрем пар канатлар куя,
Тизләтерме күршү көннәрен?
Эх, белергә иде,
Эх, белергә
Бу тормышта язмыш телләрен.

## СЕРЛӘРЕМНЕ КЕМГӘ СӨЙЛИМ

Таңнан торып чишмәләргә барам,
Болганмасын алган суларым.
Ялгыз каршыладым көннәремне,
Көткән мәхәббәтем, соңладың.

*Кушымта:*

Сөеләсем, бик сөясем килә,
Бәхет кошын көтәм ерактан.
Яшь гомерем әрәм уза инде,
Юлларыма чыкмый яраткан.

Яшь киленнәр су юлыннан килә,
Сокландыра алар язмышы.
Йөрәгемне талый, тынгы бирми,
Гел бертөрле гомер агышы.

*Кушымта* шул ук.

Күкрәү көтә җаным, түзми күптән,
Кабатланмас яшьлек язларым.
Серләремне кемгә сөйлим икән,
Мин кичерәм сөю газабын.

*Кушымта* шул ук.

## БӘХЕТЛЕ БУЛ

Иске яраларны кузгатма син,
Төшләремә һаман керәсең,
Бергә йөргән таныш сукмаклардан
Көлә-көлә миңа киләсең.

*Кушымта:*

Күзләреңдә күрәм: моң-сагыш бар,
Төшләремә кайчан керсәң дә.
Авыр сүзләр әйтмим, теләгем шул:
Бәхетле бул кайда йөрсәң дә.

Иске яраларны кузгатма син,
Юлларыбыз читләп үтелгән.
Җәй артыннан сары көзне көтәм,
Гомер йомгаклары сүтелгән.

*Кушымта* шул ук.

Иске яраларны кузгатма син,
Борчуларга салма кабаттан.
Тормыш сынавына сызланма син,
Язмыш безне шулай яраткан.

*Кушымта* шул ук.

## СИНЕ ЮКСЫНАМ

Тәрәзәңә үрелеп гөлләр үсә,
Гөлләреңә сулар сибәрсең.
Күгәрченнәр кебек серләреңне,
Әй, чибәрем кемгә сөйләрсең.

Иртән-кичен өй турыңнан узам,
Карашымны минем сизмисең.
Моңсу күзләреңне юлга төбәп,
Әй, чибәрем, кемне күзлисең.

Күк өстендә янган йолдызлар күп,
Барысы да миңа ят сыман.
Уйларымнан чыгып торганың юк,
Әй, чибәрем, сине юксынам.

## БЕҖ СУЛАРЫ

Ярга таша
Язгы сулар,
Саллар кузгала башлый.
Дулкын кага,
Сулар ага,
Ташкыннар ярсып ташый.

*Кушымта:*

Әй, Беҗ буйлап,
Беҗ буйлап,
Сал ага сулар буйлап.

Су өсләрен
Моңга күмә
Таңда сайрашып кошлар.
Ак канатлы,
Ак җилкәнле
Үтә дә китә кышлар.

*Кушымта* шул ук.

Ташуына,
Ярсуына
Куәт бирә — тоямын.
Болыныннан,
Тугаеннан
Гөл-чәчкәләр җыямын.

*Кушымта* шул ук.

## СИНЕ УЙЛЫЙМ

Ялгыз узган көннәремне саныйм,
Барысы да күргән төш сыман.
Ерак китеп, аерым яшәсәк тә,
Сине уйлыйм, сине юксынам.

Истән чыкмый гүзәл яшьлегебез,
Күзне кызыктырган сафлык бар.
Юлларыбыз безнең кушылмады,
Кая китте көткән шатлыклар?

Теләкләргә ирешмичә калдык,
Уфтандыра икән соңыннан.
Бергә каршылаган якты таңны,
Йөргән сукмакларны сагынам.

## ТУГАН ЯК МОҢЫ

Йолдызлар елмайган чакта
Күк йөзе балкып яна.
Бишек җыры алып керде
Туган як моңын җанга.

*Кушымта:*

Туган якка кайтам инде,
Сагындым талларымны.
Сандугачларны сайратып,
Каршылыйм таңнарымны.

Яшьлек хисләрен тоямын,
Кырларга чыгып йөрсәм.
Шатлыкларым ташып чыгар,
Туган як ямен күрсәм.

*Кушымта* шул ук.

Дәвалар эзләп карадым,
Тынгы юк йөрәгемә.
Нигез ташлары тартамы
Туган як төбәгенә.

*Кушымта* шул ук.

## ЧИК КУЙДЫҢ САГЫШЫМА

Буә суларын эчтеңме,
Тугайларны кичтеңме?
Борма-борма сукмагыннан
Су алырга төштеңме?

*Кушымта:*

Күптән көткән хыялым син,
Очырадың юлларымда.
Мәхәббәт сүзен сөйләргә
Керәсең җырларыма.

Икәү генә урап чыктык
Чәчкәле тугайларын.
Сөю хисләрен яңарта,
Сайраган тургайлары.

*Кушымта* шул ук.

Йөрәк ярсуы кушыла
Буәнең агышына.
Бәхет кошым синдер, бәлки,
Чик куйдың сагышыма.

*Кушымта* шул ук.

## ЯШӘСӘК ИКӘН БЕРГӘ

Мәхәббәт утында көйрәдем,
Газаплар кичерде йөрәгем.
Ямансу, бик моңсу көннәрем,
Белмәдем язмышым телләрен.

*Кушымта:*

Аерылган сәгатьләр, минутлар
Әрнетә бәгырьне гомергә,
Юксыну, борчылу белмичә,
Яшәсәк икән без гел бергә.

Күңелең сагышы бетмәде,
Томанлы күзләрең, яшьлесең.
Еракта ялгызың зар булып,
Син дә бит сагынып яшисең.

*Кушымта* шул ук.

Төшемә керәсең син һаман,
Кагылдың авырткан ярама.
Үкенәм, борчылам гомергә,
Җиде ят керде шул арага.

*Кушымта* шул ук.

## ТАЛПЫНАМ, КАНАТ КАГАМ

Ак каеннар юксындыра,
Җирсүләрем бетмәде.
Туган туфрак тарта җанны,
Уйландыра үткәнне.

*Кушымта:*

Моңнары ташып түгелә,
Чишмә суларын алам.
Туган җир күгендә генә
Талпынам, канат кагам.

Утка керәм, суга төшәм,
Көч-гайрәт бар иңемдә.
Каз юллары буйлап очып,
Кайтам туган илемә.

*Кушымта* шул ук.

Сагынганда сагышланам,
Аңладым ялгышымны.
Оясыннан очкан кошка
Тиңләдем язмышымны.

*Кушымта* шул ук.

## ЯШЬЛЕГЕМ КАЙТАВАЗЫ

Зәңгәр яулык болгап озатып калдың
Борма-борма юллар чатында.
Ара ерагая барган саен,
Мин борылып карыйм артыма.

*Кушымта:*

Серле йомгак төсле тормыш юлы,
Еракларга китеп урала.
Мәхәббәтем кай тарафка китте —
Зәңгәр яулык болгап югала.

Гүзәл яшьлек, еллар канатында
Күтәрелдең офык артына.
Шатлык-сагышларым яңарганда
Күңел һәрчак сиңа тартыла.

*Кушымта* шул ук.

Яшьлегемдә сөйгән ярымны мин,
Эзләп табармын бер ничек тә.
Вәгъдәләшеп, әгәр каушалмасак,
Үкенечкә кала яшьлек тә.

*Кушымта* шул ук.

## ХАН ЧИШМӘ

Тау куенында Хан чишмәсе,
Тынып тормый гөрләде.
Тирә-ягы нурга тулы,
Назландыра гөлләре.

*Кушымта:*

Сылу кызлар суга килә,
Чиләге иннәрендә.
Мәхәббәт җырын ишетәм
Сандугач телләрендә.

Яшь наратлар канатлана,
Хан чишмә моңнарына.
Ак бәхетләр юрап тора
Бормалы юлларына.

*Кушымта* шул ук.

Таңнар елмаеп уяна
Хан чишмә агышына.
Туган җирнең моңы арта
Чыңлаган тавышына.

*Кушымта* шул ук.

## КАРАШЫҢНЫ САГЫНАМ

Күзләреңә карап туялмадым.
Карашларым синдә тукталды.
Сөю хисе җанны тетрәттереп,
Йөрәгемне сүнмәс ут алды.

Төштә күргән кебек кенә калдым,
Бер мизгелдә китеп югалдың.
Борчуларга салма юксынганда,
Очыраштырмас бәлки юлларым.

Карашларың сагындыра мине,
Ятларга тик аны сер итәм.
Узар шатлык кына булсаң онытам,
Көткән бәхтем булсаң — кил, иркәм.

## КҮЗ НУРЛАРЫҢ

Синең күзләргә карыймын:
Зәңгәр күл сыман тирән.
Сихри моңлы, сергә тулы,
Сагыш та — барын күрәм.

*Кушымта:*

Матур карашларың белән
Иркәләдең, назладың.
Күз нурларың алып килде
Миңа сөю назларын.

Ике күзең ике йолдыз,
Балкый күңел күгемдә.
Сөюем хак, исемеңне
Саклыйм йөрәк түремдә.

*Кушымта* шул ук.

Синең күзләр гашыйк итте,
Йөрәгем сагышлана.
Тормыш маягым бул, иркәм,
Гомерем агышында.

*Кушымта* шул ук.

## ГАФУ ИТ СИН, МӘХӘББӘТЕМ

Гайбәт сүзләре ишеттек,
Сөеп сөелгән чакта.
Мәхәббәт уты сүнмәсен,
Гомергә, иркәм, сакла.

*Кушымта:*

Гафу ит син, мәхәббәтем,
Ярсыма әле, күңел.
Мин дә сагышларга төштем,
Сиңа да җиңел түгел.

Гайбәт сүзләре ишеттек,
Ятлар бар да үч итә.
Гашыйк булып, сердәш булып,
Яшәгәнгә ни җитә.

*Кушымта* шул ук.

Гайбәт сүзләре ишеттек,
Вәгъдә куешканда.
Күпләр көнләшеп йөриләр,
Без бергә кавышканга.

*Кушымта* шул ук.

## ЙӨГЕРЕП КАРШЫ ЧЫГАМ

Җиккән атлар ярсып кешни,
Юлга төште күзләрем.
Төрле уйлар кичерәмен,
Сагышланды йөзләрем.

*Кушымта:*

Кыңгыраулы атлар чаба,
Эрактан килә сыман.
Яшьлегем чакыра мине,
Йөгереп каршы чыгам.

Тирән күлдәй дулкынланам,
Белгәнгә сәбәпләрен.
Татлы хисләрем балкыган,
Кадерле сәгатьләрем.

*Кушымта* шул ук.

Чапкан атлар тоягыннан
Очкыннар оча гына.
Онтылмас якты хатирәм,
Атылам кочагыңа.

*Кушымта* шул ук.

## БҮӘ БУЙЛАРЫНА КИЛМИСЕҢ

Яшел тугайлары шау чәчәктә,
Сайла гына — кайсын телисең.
Мин чәчәкләр җыеп йөрдем сиңа,
Нигә, иркәм, шунда килмисең?

Сабан тургайлары канат кага,
Энҗе бөртекләре чыкларда.
Буә буйларына мин киләмен
Сине бик сагынган чакларда.

Төнбоеклы суда йөзәр идем,
Кочар идем зифа камышын.
Акчарлагы үткәндә кычкырып,
Охшатамын сиңа тавышын.

## СИҢА ӘЙТЕР СҮЗЛӘРЕМ БАР

Яшь гомер узар да китәр,
Сизелми кала еллар.
Очраштыра, күрештерә,
Чакырып тора юллар.

*Кушымта:*

Сиңа әйтер сүзләрем бар,
Ямьле язларым үтә.
Бер күрешеп сөйләшергә
Күңелем сине көтә.

Очып кил син, акчарлагым,
Көттермә, соңга калма.
Юксынам да, борчылам да,
Сагыш утына салма.

*Кушымта* шул ук.

Серем дә син, моңым да син,
Теләкләр чикләнмәсен.
Тормыш кочагында назла,
Сөюдә шикләнмә син.

*Кушымта* шул ук.

Уйланып сулар сибәмен
Сусаган гөлләремә.
Ышаныч белән яшимен
Бәхетле көннәремә.

*Кушымта* шул ук.

**БИРЕШМӘ КАЙГЫЛАРГА**

Аклыгын-сафлыгын саклый,
Карыймын каеннарга.
Җил-давыллар кагылса да,
Бирешми кайгыларга.

*Кушымта:*

Бер ялгызым уйга төшәм,
Уйлар диңгезе тирән.
Тормыш газабын күрсәтә,
Башны imәдем түбән.

Аклыгын-сафлыгын саклый
Аккан чишмә сулары.
Узган гомерне кисәтеп,
Күңелгә моң чорналды.

*Кушымта* шул ук.

Аклык-сафлыкка табынам,
Җирдә гөл-чәчкә үссен.
Күрмәсәм, белмәсәм иде
Кайгы-хәсрәтләр төсен.

*Кушымта* шул ук.

## ТУГАН ҖИРЕМ, БЕРГЕНӘМ

Йөрәгем белән тоямын
Туган җирнең жылысын.
Якты көннәр алып килә
Шатлыгымның зурысын.

*Кушымта:*

Туган җирем, бергенәм,
Кадерлисең син, беләм.
Гомер язымны бизәдең
Бәхетле язмыш белән.

Игеннәрем кырда шаулый,
Аккошлар күлгә төшә.
Гүзәл Җирем күңелемә
Матур җыр булып күчә.

*Кушымта* шул ук.

Бәрәкәтле туфрагыңнан
Яшәвемә көч алам.
Җир, яменне күрсәтәсең,
Мин синең газиз балаң.

*Кушымта* шул ук.

## ДУЛКЫННАР ЯРГА КАГА

Яр буйларын таллар төргән,
Күл читеннән урадым.
Йөгереп йөргән дулкыннарга
Гаҗәпләнеп карадым.

Дулкыннарның ярсу чагы,
Ташыймы яшьлек дәрте.
Канат кагып сайрар кошлар,
Тирәкләрен тибрәтте.

Үткәннәргә алып килә
Йөргән бар сукмакларым.
Йөрәк ялкынын өстәдем,
Сүнмәсен учакларым.

Җырга җыр килеп кушыла,
Дулкын дулкынны кага.
Узган көннәрнең шатлыгын
Күңелем эзләп таба.



# Поэмалар

## КӨН КАРШЫНА КИЛӘМ

### I

Таң яктысы тәрәзәмә төшә,
Анам кебек назлап уята.
Туар көнем нинди булыр икән,
Төрле уйлар мине уйлата.

Аяз торыр микән күкләр бүген,
Кошлар сайрармы соң тирәктә?
Сорауларым үз җавабын көтә —
Чират алган бар да йөрәктә.

Күзне ачам: дөнья имин микән?
Караш салам тирә-юнемә.
Тормыш чаңы колагымнан китми,
Алып килә яңа көнемә.

Яңа көнем шатлык китерерме,
Теләкләрем чынга ашармы?
Күңел кошым канатларын җәеп,
Биек үрләр яулап кочармы?

Бер ышаныч кирәк яшәгәндә,
Боз яуса да, давыл купса да.
Баскан җирем кинәт тетрәсә дә,
Салкын җилләр килеп какса да.

Киләчәгем, күрәчәгем дәшә —
Яңа көнгә караш төбәлә.
Тал чыбыгы итеп бөгә инде,
Шикле кичерешләр терелә.

Адәм баласының юлы урау,
Киртәләрне кирәк сүтәргә.
Шома гына, тыныч кына булмас,
Гомер юлын кирәк үтәргә.

Бу дөньяга төрле афәт туа,
Кешеләрне ахры кисәтә.
Кылган гөнаһлары җирдә күптер —
Җәзаларын Аллам күрсәтә.

Һәркем күрә тәкъдирдә язганын,
Беркем калмый мәхрүм өлештән.
Дуслар кирәк авыр минутыңда
Кайгы-шатлыгыңны бүлешкән.

Көн каршына чыга күбәләкләр,
Бал кортлары оча болынга.
Назларын да, ямьнәрен дә бирә —
Кояш карый көлеп барына.

Иртән оча кошлар оясыннан,
Кырмыскалар эшкә йөгерә.
Җилләр исә үлән битен сөеп,
Басуларда иген өлгерә.

Җиһан кергән изге сәгатенә:
Кошлар сайрый чишмә түрендә.
Ак каеннар купшыланып кына,
Яшел шәлләренә төренә.

Иртән килә казлар яр буена,
Үлән ашап, суда коена.
Көмеш тәңкә кебек чыңлап кала —
Чык бөртеге җиргә коела.

Аулак сукмаклардан килеп чыга
Болан балаларын ияртеп.
Тормыш кануннарын, бар белгәнен
Аналары йөри өйрәтеп.

Кемнәр кайта арып вахтасыннан,
Кемнәр әле эшкә җыена.
Үз шөгылем булсын шатландырган,
Төшенермен тормыш җаена.

Олы юлга чыгам максат куеп,
Яшермәмен булган шигемне.
Каршы төшкән биек киртәләр дә —
Минем алда бар да чигенде.

II

Малай чакта атлар саклап йөрдем,
Булды кырда көтү көткәнем.
Чыныкмаган чактан иңнәремә
Икеләнми эшләр йөкләдем.

Гармунчы булам дип уйлар кордым,
Каян килгән шундый теләктер,
Умырзая кебек шытып чыкты,
Мәңге шиңмәс минем йөрәктә.

Йөрәктәге моңны-сагышларны,
Гармун телләреннән сөйләтим,
Күңелләрем бер бушансын әле, —
Юаныргa әмәл өйрәним.

Табыннарда гармун уйнатасым,
Җырлатасым килә минем дә,
Шул уемнан арнып торганым юк
Иртәләрен, көнен, төнен дә.

Гармуннарның күрекләрен сузып,
Ашкындырып килә уйныйсым.
(Тормыш нигә төрле сорауларың,
Сынауларың миңа куясың?)

Гармун тавышларын ишеткәндә,
Тынычлана алмам беркайчан.
Көзге көннәр кебек сагышлымын,
Тумыштан ук гамьле, мин уйчан.

Авылда күп оста гармунчылар,
Барып йөрдем алар өенә.
Өйрәтегез, димен, уйнатырга,
«Баламишкин», «Сарман» көенә.

— Әхмәт абый, әйдә, өйрәт мине,
Гармун телен ничек белергә?
Җаным тели, өйрәнермен төсле,
Шундый изге хисләр терелә.

Халык моңын, халык дәртен тоям,
Гомер бакый, беләм, җырлаган.
Күпләр кайгы-хәсрәтләргә тарып,
Авыр хәлгә калып зарланган.

Бөдрә башлы чабаталар киеп,
Заманында йөрдек клубта.
Безнең буын булдыксыздан түгел,
Җебекләрдән түгел холык та.

Күршем булды, дус та булды Хәмит —
Бергә үстек, бергә уйнадык.
Уртак итеп бөтен серебезне,
Килер көн хакында уйландык.

Зәңгәр иртәләрне каршыладык,
Шәфәкъ алсулыгын күзәттек,
Хыялыбыз чынга ашсын берүк,
Көткән шатлыкларны тизләттек.

Тәвәкәллек, кыюлык та кирәк, —
Хәмит белән күптән аңладык.
Игътибарлы булдык һәрчагында, —
Йөрәк кушканын без тыңладык.

Бөркет баласы күк горур карап,
Ижау каласына юл алдык.
Туган йортны ташлап китү кыен,
Ихтыяр, көч табып юандык.

Укырга да, эшләргә дә теләк, —
Көнебезне күрик, ашыктык.
Шәһәр урамнары шаулы, ямьле,
Бер күрүдән аны ошаттык.

Тәүдә озак эш тапмыйча йөрдек —
Борын суыбыз да кипмәгән.
Тормыш юлын ничек башлап китик —
Бер кеше дә безне көтмәгән.

Җырлыйсы да, елыйсы да килде —
Шәһәр урамында адаштык.
Озак йөргәч эш урыны эзләп,
Кирпеч заводына урнаштык.

Монда башкачарак дөнья хәле:
Кемнең кем икәнен белмисең.
Бикле торган йорт шикелле инде,
Җиде ятка сер дә бирмисең.

Авылдан гел хатлар килеп торды,
Чакырдылар өйгә кайтырга.
Күңелләрдә сагыш, сагыну бар,
Туры килә барын татырга.

III

Мастер Хәйрүш — кырыс, яман кеше,
Миһербансыз, усал карашы.
Уңай якка бер сөйләми эшне,
Юк, йөзенә килми карыйсы.

Җикеренә башта безне күреп,
Ничә төрле килеп эш куша.
Эй, сез колхоз малайлары, диеп,
Каршыбызга башта ул баса.

Уңын-суңын бер дә карап тормый,
Төрле якка кирпеч озата.
Бушка түгел, калым юарсыз, ди,
Эш сәгатен безнең озайта.

Катлы-катлы күпләр дача сала,
Кемдер йортлар төзи бу көндә.
Нәфсе колы булып яши инде,
Белмиләр дип уйлый беркем дә,

Эштә Хәйрүш гел кызмача йөри,
Арлы-бирле иртән сугыла.
Атасын да, анасын да куймый,
Ак-караны белми сүгенә.

Айлар, көннәр йөгерешеп үтә,
Күп нәрсәгә тормыш өйрәтте.
Мастер Хәйрүш йогынтысыдыр бу:
Хәмер эчәм, сигар көйрәтәм.

Гармун алырга һич акчам җитми —
Дусларыма юкка мактандым.
Буш кул белән кайттым авылыма —
Сәбәпләрен табып акландым.

Күңелемә күчә бара минем
Якты көнем, төнем, кичләрем.
Максатыма ничек ирешергә,
Иренемне кайчак тешләдем.

Күкрәгемне куеп алга барам, —
Йөзләремә бәреп җил исә.
Җанга рәхәт, якты өметләрем
Йөрәгемдә сүнми йөресә.

Яңа шыткан үлән хәлендә без,
Кырау төшә, җилләр кагыла.
Авырлыклар очырап кына тора,
Яшәү дәрте сүнми — кабына.

Гаделсезлек кайчан бетәр җирдә,
Дөрес япмый мастер нарядны.
Кемнәр сыйлый, кемнәр кунак итә —
Шундыйларны бары яратты.

Эш хакыбыз түбән, акчасы юк,
План үтәлми, ди, хуҗалар.
Йон йомгагы кебек итеп сүтә,
И камчылый мине нужалар.

Хәйрүш кебекләр тик пошынмый һич,
Ил байлыгын җилгә очыра.
Кырын эшләр кыла бик яшерен,
Чыгалмыйсың мәңге очына.

Үз хәстәрен алар күреп яши,
Бу тормышның эчә өресен,
Җиңел дөнья көтми эшче халкы,
Язмышында күрә төрлесен.

Ел башында йөкләмәләр алып,
Түрәләр тик бары куана.
Ай азагы җитсә, бар эшчене
Кирәк, диләр, эштән куарга.

Тукран тәүбәсенә охшый бу хәл,
Кабатланып тора ел буе.
Түрәләрне эштә күргән дә юк,
Аңлашылмый шайтан-җен туе.

Кирзаводның эшен кем дә белә:
Кулга алган кирпеч ватыла,
Түбән сыйфат белән чыгарыла,
Арзан бәяләнә хакы да.

Мастер Хәйрүш — калай әтәч инде:
План үтәлә, дип мактана.
Алга китеш әмма һич сизелми,
Бер урында эшләр таптана.

Кызык түгел уңыш яуламагач,
Татымагач хезмәт җимешен.
Гаепләләр фаш ителми кала,
Йөз кызара бүген кем өчен?

Айлар, көннәр үтеп кенә тора,
Юаныч юк, күңел борчыла.
Сәбәпләрен эзләсәң дә аның,
Чыгалмыйсың мәңге очына.

Хуҗасыз йорт кебек эш мәйданы,
Завод түрәләре пошынмый.
Иртәгәсе көнең яхшырыр дип,
Кем әйтсә дә, күңел ышанмый.

Баш имәдек, күкрәк куеп бардык,
Йөзгә бәреп искән җилләргә.
Утларына кердек, суларына төштек,
Тормыш авырлыгын җиңәргә.

Җирдә яшәү җиңел түгел икән —
Яшь булсак та моны аңладык.
Бәхет эзләп килеп чит шәһәргә,
Хәмит белән әллә уңмадык?

Авылга да кире кайтсак оят,
Дуслар безне ничек аңлар соң?
Кешеләрнең олы ышанычын,
Бер югалтсаң, ничек яуларсың?

Гел бер сорау баштан чыгып тормый,
Мин табалмыйм аның җавабын:
Дөрес юлны сайлап алдык микән,
Шуны уйлап көям, янамын.

Тулай торагында ир-егетләр
Эштән кайткач хәмер эчәләр.
Аһ-зарларын бергә бушаталар,
Шау-шу белән уза кичәләр.

Шаулы кичәләргә ияләндек,
Ятимнәр күк читтә калмадык.
Дуслар таптык, бергә күңел ачтык,
Гомер уза бушка — аңладык.

Иртән торып эшкә ашыгабыз,
Кабатлана бер үк шөгыльләр.
Җирләр казып, балчык ташып көн дә,
Яшьлек уза — шуңа шигем бар.

Кулдан килгән, көч җитәрлек эшне
Эзләсәк тә, барыбер тапмадык.
Үзгәрмәде, гел бертөрле тора,
Шәп түгел шул эшләр мактарлык.

Арысак та, егылсак та инде,
Беркемнән дә ярдәм көтмәдек.
Узган елны Хәмит белән икәү
Конкурстан вузга үтмәдек.

Бәхет кошы очып килер, дидек,
Көттек аны, көттек ышанып.
Өмет-хыяллар да акланмаса,
Белмим хәзер кемгә охшадык?

IV

Ял көннәре җитсә Хәмит белән
Шәһәр паркларын урадык.
Ак күлмәкләр киеп купшыландык,
Матур итеп чәчләр тарадык.

Төрләндерә тормыш күптөрлегә,
Хөкем кыла адәм баласын.
Көннәр-төннәр алмашынып тора,
Без күргәндәй агын-карасын.

Әни чакыра һаман авылыбызга,
Яза бик еш миңа хатында:
«Яшьсең, улым, берүк саклана күр», —
Кисәтә ул эчке хакында.

Өзгәләнә әни, хафалана,
Күңеленнән газап кичерә.
Җил иссә дә безнең тарафлардан,
Сагышланып искә төшерә.

Офыкларга төбим күзләремне —
Кошлар оча кайсы тарафка?
Туган җирнең сүнмәс яме, моңы
Сыеп бетәр минем карашка.

Күз күрмәгән чит шәһәрдә яшәп,
Туган якның белдек кадерен.
Ерак араларны якын итеп
Йөгереп кайтырга да әзермен.

Юксынамын сәхрә-кырларымны,
Малай чакта йөргән юлларны;
Су буенда казлар саклап узган,
Чыклар ярган яшьлек елларны.

Мин күнгәнмен барысын да күреп:
Фани дөнья алдый — төшенәм.
Кешеләргә бәхет өләшергә
Килсен иде минем көчемнән.

Җирләр казыйм, ташлар ватам көн дә,
Бар булмышым, шундый хезмәтем.
Шатлыгымны юллыйм, эзлим аны,
Килер сәгатьләрен тизләтәм.

Тау бөркете кебек җаным горур,
Мин көчсез дә түгел, мескен дә.
Язмыш, хәер, төрлечәрәк инде,
Сынап карый яшьтән үскәндә.

Яңа көнгә багам өметләнеп,
Максатыма карап юнәләм.
Әз булса да, уңышларым да бар,
Бер ышаныч белән юанам.

Быел язлар соңга калмасмы соң,
Корыр микән кошлар оясын?
Туган җирдән язмыш алып китте,
Безнең бәхетебез кайда соң?

Кошлар кебек пар канатым булса,
Очып йөрер идем иректә.
Сагындыра туган җир төбәге,
Чит җирләрдә язмыш йөр(е)тә.

Язлар көтәм, ташу алып килсен,
Күңел сагышларым юылсын.
Өндәгеләр белән саташамын,
Күргән төшне ничек юрыйсың?

Өй артында үскән тупылларым,
Юксынганга әллә шаулыймы?
Искән җилгә сәламнәрен әйтеп,
Колагыма килеп чыңлыймы?

Хәмит дустым, авыл төшкә керә,
Кайтыйк әле сабантуена.
Әйтерсең лә йөз ел күргәнем юк,
Миңа никтер озак тоела.

Авылыма кайткач Акчишмәдән
Сусауларны баса — су эчәм.
Малай чакта җиләк җыеп йөргән
Яшел тугайларны мин кичәм.

Сакат тауга менеп каеннарның
Чукларыннан сөеп тарармын.
Якты хатирәләр яңарырлар, —
Авыл урамыннан узармын.

Бергә үскән дуслар кайда хәзер, —
Барлап чыгам алар язмышын.
Фани дөнья гел кисәтеп тора,
Сизелми дә гомер агышым.

Өмет белән яшим ни күрсәм дә,
Башны тотам горур, югары.
Юлларыма ятлар киртә кора,
Бирешергә исәп юк әле.

Заманалар чуар, михнәтләр күп,
Төрлечәрәк, тормыш, сынадың.
Таллар кебек җиргә бөгелдем мин,
Бөгелсәм дә ләкин чыдадым.

Ир-егетләр килгән төрле-яктан,
Хезмәт мәйданында дуслаштык.
Каткан икмәкне дә уртак каптык,
Йотым суны бүлеп кысташтык.

Торак йортта тормыш шаулап тора,
Монда яшьләр кичен гөр килә.
Кемдер җырлый, кемдер гармун уйный,
Яшьлек дәрте, моңы бөркелә.

Аруымны онытам эштән кайткач,
Бүлмәбезгә дуслар җыела.
Кемдер билет алган театрга,
Кемдер паркларга җыена.

Көнем, төнем, аем бер-бер артлы,
Дәрья суы кебек агыла.
Ниләр генә баштан кичерсәм дә,
Матурлыкка йөрәк табына.

Яшь чагында артык төпченмисең,
Белгертмисең барын ятка да.
Әллә нинди хәлләр баштан уза,
Авылыма язмыйм хатка да.

V

Ил өстендә төрле хәбәр йөри,
Күкрәү булып кинәт ишелә.
Хакыйкатьне юллый гомер буе,
Бик күп нәрсә җитми кешегә.

Мәскәү оран сала иртә-кичен,
Радио сөйли бер хакта.
Яңа баштан илне үзгәртергә
Вакыт җитте, диләр, бу чакта.

Үзгәртергә дигән чакыру белән
Тулып чыга гәзит битләре.
Кайсы якка, нинди юл сайларга, —
Уйландыра хәзер күпләрне.

Төрле фикер, төрле караш туа,
Уйларыма уйлар кушыла.
Заман сынауларын алга куеп,
Язмыш баса килеп каршыма.

Хезмәт сөям яшьлек дәрте белән
Тормыш үрләренә үрләргә.
Уттан алып суларына сала,
Сабырлык бир, Ходай, ирләргә.

Ил өстенә күкрәү аваз сала,
Сискәндерә кинәт халыкны.
Үзгәртергә, дигән яңа оран
Көтмәгәндә килеп калыкты.

Кемнәр икән дәгъваләшә тагын,
Ил корабы кая юл тота?
Шикле шом тудыра килер көннәр,
Кеше курка, бар да ут йота.

Югарыдан әмер килсә халык,
Чакыруларга күнгән — ышана.
Бу юлы без ялгышмаска тиеш,
Бер фикердә булыйк, иншалла!

Ил тезгенен тоткан зур түрәләр
Кайсы юлны сайлар — билгесез.
Уңарбызмы алда, туңарбызмы —
Иртәгәсе көнне белмибез.

Уңай якка тормыш үзгәрерме,
Яңалыкка борып карашын.
Залим затлар хаким булып калса,
Аермаслар агын-карасын.

Өч йөз алтмыш градуска булсын,
Борылырга әзер торамын.
Бу дөньяны матурларга кирәк —
Шундый якты план корамын.

Мин Җиһанда йолдыз булып балкыйм,
Каен булам — төшсен аклыгы.
Ышанамын: теләк булса, Җирдә
Җәннәт төзер кеше акылы.

Тормыш яме алып килсәк икән
Яңа көннәребез каршына.
Кояш кебек кешеләргә карыйм,
Шатлык өләшәмен барсына.

## АВЫЛЫМ КЕШЕЛӘРЕ

Өченче көн бер туктамый буран,
Җил ыжгыра, карлар себерә.
Җылы тапмый, калтырана тәнем,
Җаным өши, каным сүрелә.

Буран тавышы колагымнан китми,
Аһ-зарын ул миңа көйләде.
Күк белән җир бергә тоташкан,
Кар астында авыл өйләре.

Эт тә йөрми, тычкан эзе дә юк,
Сукмак бетте якын күршемә.
Нинди куркыныч һәм шомлы, ямьсез
Афәт яный бөтен кешегә.

Беркем узмый, бушап калган урам,
Тау-тау булып карлар өелгән.
Аваз-тын юк, ишетелми бер дә,
Кеше йөрми чыгып өеннән.

Иртән-кичен тәрәзәмә килеп,
Күк бозларын эретеп карадым.
Күңел белән ерак сәхраләргә,
Басуларга чыгып урадым.

Почтальоннар йөр(е)ми ничә көн,
Хат-хәбәрләр күптән алган юк.
Көткән кешеләрем килми кала,
Мин тормышта яшим алданып.

Районга барыр әмәл калмый,
Сукмакларым, юлым өзелде.
Язы-көзе була шундый ук хәл,
Авыл халкы, мескен, түземле.

Бу көннәрдә күрше Хәлил бабай
Үлем көтеп ята түшәктә.
Зарланмый ул, хәтта сер дә бирми,
Хәлен белеп көн дә керсәк тә.

Улы-кызы Уренгойда яши,
Сирәк кайта ата йортына.
Карчыгы да былтыр көзен үлде, —
Зиһен кайный, уйлар йотыла.

Сүзсез калам, уйланам да үзем,
Буран тавышларын ишетеп.
Ачы җилләр укси-укси елый,
Кемнең язмышына үч итеп?

Мондый чакта автовокзал тулы:
Машиналар йөрми авылга.
Кем йөрәге җитеп юлга чыксын,
Күз ачкысыз көчле давылга?

Җәфа чигә авыл кешеләре,
Яңгыр яуса, буран булса да.
Туган җирең сине чакырып тора,
Өшесәң дә барыбер, туңсаң да.

Хәлил бабай бер ялгызы калды,
Күрше-күлән керә янына.
Сулыш җитми, ыңгыраша үзе,
Урын табалмыйча җанына.

Вакыт агышлары тынып тормый,
Җилләр сыман җитез йөгерә.
Борчылу бар бүген күңелемдә,
Төрле уйлар башта өлгерә.

Биш ел йөргән сугыш кырларында,
Авыр яра алган үзенә.
Хәлил бабай нинди өмет белән
Моңсу гына карый күземә?

Авыл кешеләре игелекле,
Ярдәм итә, шәфкатьне белә.
Кирәк чакта бер телем икмәген
Унар өлеш итеп ул бүлә.

Хәлил бабай хәлен авыл белә,
Аш-суыннан һич тә кызганмый.
Ничә көннәр-төннәр ята инде,
Урыныннан бер дә кузгалмый.

Күптәнмени әле карчыгын ул
Соңгы юлга елап озатты.
Авыл картлары гел китә тора,
Юксындырып җанны, сызлатып.

Бер ялгызы калып яшәгәчтен,
Кайгы —сагышларга тарыды.
Тормыш утларында тетрәп янды,
Авырлыклар күреп арыды.

Ике күзләп улын-кызын көтә,
Карашлары кала ишектә.
Безнең ничек ымлап сөйләшкәнне
Хәлил бабай ахры ишетә.

Иртән-кичен көтте: кайтмый алар,
Хәбәр җибәрсәк тә чакырып.
Кипкән иренена су тидердек,
Торалмады үзе утырып.

Әкияттәге сыман табигать тә —
Ак бураннар кинәт тукталды.
Җилләр кая китеп йоклый икән,
Баскан җирем, күгем тын калды.

Хәлил бабай улын-кызын күрми,
Мәңгелеккә йомды күзләрен.
Фани дөнья өчен янып-көйми,
Карап тордым моңсу йөзләрен.

Авылым халкы көн дә кими бара,
Сәбәпләрен беләм: күптөрле.
Нигә күз йомалар икән — белмим,
Шундый хәлгә кемнәр китерде?

Авыл кешеләре өметләнә
Кар яуса да, яңгыр яуса да.
Забастовка алар ясамады
Суга төшсә, утта янса да.

Урамнары бетә, йортлар калмый,
Авылым халкы читкә таралды.
Кардәшлеккә чикләр куелырмы,
Сәбәп итеп ерак араны.

Барыр җиргә баралмыйча кала,
Барса кайталмыйча интегә.
Бушка китә изге теләкләр дә,
Яшь гомерләр әрәм үтелә.

Атна-ун көне дә узып китә,
Магазинга икмәк тә кайтмый.
Газап чигә кеше, нәфрәтләнә,
Туган җиренә дә кайталмый.

Табыннарда икмәк булсын диеп,
Авыл халкы тырыш эшләде.
Шәфәкъларны якты таңга ялгый,
Бүленеп кала татлы төшләре.

Игенчеләр күрде кыр өстендә
Яңгырын да, карлы бозын да.
Күпме икмәк илгә тапшырса да,
Талон белән алды тозын да.

Бөтен көчне җигеп тарттык инде,
Кара җирдә чана сөйрәдек.
Бишьеллекның планнарын үтәп,
Горурлану белән сөйләдек.

Авыл кешеләре хезмәт сөя,
Олы максат куя гомергә.
Бушка кала бөтен эшләгәне —
Бәгырьләрне әзме кимерә.

Үр яуларга безне өндәделәр,
Түбән төштек ура кычкырып.
Кем әтәрде, белмим, шундый хәлгә,
Күп сөйлибез һаман ачынып.

Тау кадәре йөкләмәләр алдык,
Һәр тармакта план үтәдек.
Көч җитмәгән эшне йөкләттеләр,
Ризалаштык — кулны күтәрдек.

Безнең авыл урман-кырларга бай,
Шул хакта мин бик еш уйланам.
Мәшәкатьләр бетми, эшләрем күп,
Йокылардан иртә уянам.

Мин сөенәм тупылларым шаулап,
Канат кагып бөре чыгарса.
Тау ягыннан көмеш моң агыла,
Чылтыр чишмәләрең чыңласа.

Мин уйланам, авылым, синең хакта,
Тук башаклар дулкын какканда.
Игенчегә олы хөрмәт арта,
Басулардан олау кайтканда.

Табыннарда сый-хөрмәтне күрсәм,
Күздә тотам хезмәт кешесен.
Бөтен көчен бирә кызганмыйча
Авыл кешеләре эш өчен.

Язмышыбыз безне бергә җыйган,
Җирне сөюебез бәйләде.
Әллә нинди авыр чак булса да,
Максатыбыз алга әйдәде.

Заманында сыер җигеп йөрдек,
Сабаннарга ирләр җигелде.
Әллә ни булса да, халык тырыш:
Тырмалады, сөрде җиремне.

Ул чагында без малайлар идек,
Буразналар буйлап йөгердек.
Орчык кадәр генә булсак та без
Сабан тотарга да өлгердек.

Хәтерлимен ерак калган язны,
Кави абый кайтты сугыштан.
Сугыш бетте, җиңеп кайттык, диде.
Шатлык белән күңел тулышты.

Исән калган ирләр илгә кайтты.
Каршыладык без дә сөенеп.
Тол хатыннар сагыш кичерделәр,
Кайнар күз яшенә төелеп.

Акчишмәгә иртә-кичен килде
Су алырга кызлар, киленнәр.
Яңа көнгә кердек шатлык көтеп,
Гел ашкынып торды күңелләр.

Кыр эшләре беткәч, бөтен авыл
Җыела иде олы җәйләүгә.
Гармун уйнап, яшьләр җырлый анда,
Бик күңелле булды җәйләрдә.

Кави абый председатель булды,
Халык аны үзе сайлады.
Һәркем аңа өметләр баглады,
Абруйлы кеше санады.

Авылымның чын хуҗасы булды,
Иртән-иртүк чыкты кырларга.
Алын-ялын белми игенчеләр,
Шәфәкъларны ялгый таңнарга.

Тол хатынга, ятим балаларга
Иң беренче бирде икмәкне.
Байлык җыеп нәфес арттырмады,
Кулланмады андый хикмәтне.

Кышлар җитсә, урман кисеп йөрде,
Йортсыз кешеләргә йорт салды.
Шәфкатьле дә, мөлаем да булды,
Кешеләрне һәрчак юксынды.

Печән чапты изүләрен ачып,
Покосларын чыкты иң алда.
Алла биргән аңа көч-гайрәт тә,
Матурлык та, бетмәс иман да.

Халык белән һәрчак киңәшләште —
Кайсы җиргә нәрсә чәчәргә.
Эшләгез дә, ашагыз да, диде,
Ирек бирде җайлап яшәргә.

Район хуҗалары гел кисәтте,
Ирек куясың, дип, халыкка.
Кави абый куркак түгел икән —
Төшермәде безне коллыкка.

Авыл кешесенең хәстәре күп,
Җирен сөрде, иген үстерде.
Зарланмады, хурланмады һич тә,
Гомерендә күпне кичерде.

Ашлыгы да төрлечә җыйналды —
Берчак уңды, берчак уңмады.
Күзләре дә бик ашыгып килде,
Язлары да кайчак соңлады.

Табигатьнең үз законы яши,
Кешеләрдән киңәш сорамый.
Көтмәгәндә җил-давыллар чыга,
Теләкләрне санга санамый.

Иртә төшкән карлар гаепледер,
Урылмады солы басуы.
Кави абый гаепле табылды —
Хуҗаларның килде ачуы.

Район җитәкчесе үзе килеп,
Авыл халкын бергә җыйнады.
Үз кешесен рәис итеп куйды,
Сүз кушарга беркем кыймады.

Зур корсагын киереп түрә басты,
Минем сөйләгәнне аңлагыз.
Сезгә хуҗа булыр, билгеләдем,
Яратыгыз, диде, тыңлагыз.

Шайтанга да без табындык инде,
Матур киләчәккә ышандык.
Әйтер сүзебезне әйтәлмәдек,
Җанлы курчакка гел охшадык.

Кызыл билет салган кесәсенә,
Күпләр түрә булды колхозга.
Машиналар алып, йортлар салып,
Яшәделәр — шуңа кан кыза.

Отчет биреп эшләмәгән эшкә,
Колхоз малын күпләр өләште.
Типтерделәр, туеп сикерделәр,
Бер-берсеннән хәтта көнләште.

Коммунизм кыры күренә дип,
Алдадылар әзме халыкны.
Ак-караны хәзер аерабыз,
Кем икәнен алар таныттты.

Лозунглар койма башларында,
Чакырып торды план үтәргә.
Бишьеллыкка йөкләмәләр алдык.
Мул тормышны кайчан көтәргә?

Төрле еллар булды, төрле чаклар,
Бодай чәчми, кукуруз үстердек.
Туган җиргә барыбер гашыйк булып,
Авыл, синдә гомер кичердек.

Шәхес культы, торгынлык та булды —
Берсе читләп узмый авылны.
Ышанганбыз, табынганбыз юкка —
Ачыклады вакыт агымы.

Ата-баба гомер иткән туфрак —
Тик шул гына газиз, кадерле.
Гасырлардан бу көннәргә килгән —
Барсының да монда кабере.

Авыл урамнары бушап калган:
Ятим йортлар арта һаман да.
Ваба чире җиргә калыктымы,
Нигезе бетә шушы заманда.

Нинди заманага життек икән,
Алпавытлар шакый капкага.
Күп кешеләр җиңел кәсеп эзли,
Сәүдәгәрләр бар да мактана.

Авыл кешесенә нәрсә кала,
Иген иккән җирен сатсалар.
Яшәвенә ышанычы бетә,
Тамырына аның чапсалар.

Кайсы яктан тагын җилләр исәр,
Кайсы ярга дулкыннар кагар?
Тормыш куя һаман сорауларын,
Җавапларын аның кем табар?

Ата-бабаларның әманәтен
Ничек кенә хәзер акларга?
Авыр заманага туры килдек:
Йорт нигезен кирәк сакларга.

Авыл кешеләре гомер буе,
Иген игеп, муллык арттыра.
Өстәл уртасында икмәк булсын —
Кеше күңелләре яктыра.

## ГОМЕР СУКМАГЫ

I

Тәрәзәмнең пәрдәләрен ачтым —
Урамнарга төшә карашым.
Ак энҗеләр кебек карлар яуган,
Таң эреткән төннең карасын.

Кыш иртәсен серле тынлык били,
Агачларга көмеш бәс каткан.
Күзләремә тулды якты нурлар,
Юрган булып җиргә кар яткан.

Декабрьнең соңгы көне бүген,
Сагышлы моң җанда терелә.
Төрле уйлар башка килеп басты,
Төшенәлмим үзем серенә.

Сусаганмын аклык-сафлыкларга,
Сизелми дә вакыт агышы.
Фани дөнья үзгәрә дә тора —
Ак пәрдәләр корган каршыма.

Кар өсләре якты мәрҗән төсле,
Җем-җем итә — күзләр камаша.

Тирә-юньгә бәйрәм төсе кергән,
Кыш күрсәтә олы тамаша.

Урам читендәге каеннар да
Иңнәренә салган ак шәлне.
Кызлар кебек мине сокландыра,
Канатлана хисләр бу мәлне.

Чәчәк аткан чагы хыялымның,
Яшьлегенә кайтып урадым.
Изге максат белән туган җирдә,
Күкрәгендә яшим Уралның.

Кыш аенда усал ир холкы бар,
Кырыс та ул, ыжгыр суык та.
Күз ачмаслык бураннары улый,
Ачы җилләр дулый чынлыкта.

Иртәләрем тыныч уза да соң,
Моңсулата мине кичләрем.
Ваклыклардан өстен булсам иде,
Саташулы күргән төшләрем.

Көнем-төнем тоташ үтеп тора,
Сәгать чылбыры күк тезелеп.
Маңгай сырларына күзем төшә,
Көзгеләргә карыйм өзелеп.

Яңа елым ишек кага килеп,
Дусларымны җыям кичәгә.
Илем имин, дөнья тыныч булсын,
Шатлыкларым белән килсәнә.

Кыңгыраулы пар атларда чыңлап,
Бер йөрисе килә бәйрәмдә.
Мине яшьләр аңламас та хәзер —
Машинада урам әйләнә.

Бу кичәдә шампан шәрабларын
Бәллүр бокалларга салырмын.
Кайсы дуслар табынымда булмас,
Сынаса да язмыш — сабырмын.

Бер югалту күрми кем яшәгән —
Аянычлы хәлләр кичердем.
Дөнья куйган күпме дусларымны
Юксындыра, искә төшерәм.

Иртән торып күзне ачтым исә,
Күрәм: дөнья ничек чүпләнгән.
Күкләр чатный, җир тетрәп куя.
Шомланамын кайчак, шикләнәм.

Көннәремне, елларымны барлыйм,
Шигырь юлларына тезәмен.
Кар-бураннар уртасында калам,
Салкын җилләренә түзәмен.

Диңгез кебек тирән уйда калам,
Тапмыйм аның очын — азагын.
Исән-имин яшәвемә сөенәм,
Күрсәм дә күп тормыш газабын.

Кышларның да күп төрлесен күрдем,
Кары-бозы яуды башыма;
Табигатьнең үз кануны яши,
Хөкем карары бер барсына.

Кара төндә бураннарда калып,
Юлларымнан язып адаштым.
Йөрәгемне чәнчү алганда да
Тормыш белән һәрчак аңлаштым.

Күңелемә күчсен аклык, сафлык,
Гомеремнең якты мизгеле.
Матурлыкның, гүзәллекнең дә бит
Үз вакыты була, билгеле.

Кыш аеның юмартлыгын тоям:
Аклык, пакьлек, сафлык өләшә.
Җир өсләре нур балкытып торган
Җәүһәр ташларына тиңләшә.

Ел фасылы чылбырында тота
Язны, җәйне, көзне, кышны да.
Вакыт үлчәвендә тора бар да —
Җирдә аунап яткан ташлар да.

Галәм киңлегендә вакыт ага,
Тормыш сәхнәсендә чагыла.
Сунамилар таша, ай тотыла —
Дөньяның бар шундый чагы да.

Көнне төн карасы алмаштыра,
Күкне бизәп йолдызлар яна.
Миллион еллар кабатланган шулай,
Тик туар көн — һаман өр-яңа.

Гомер сукмагында бар күргәннәр
Хәтер китабыңа языла.
Киләчәкне күңел күзем белән
Бер күрергә иде аз гына.

Яз тавышы керә колагыма,
Тамчылары тама тып та тып.
Кыйбла яктан саба җиле исә:
Кулдан килми — булмый туктатып.

Вакыт җиткәч карлар эреп агар,
Ерганаклар гөрләп юл салыр.
Бер мизгелдә барын хәл итәсең,
Ашыкмале, вакыт, ит сабыр.

Узган язлар төшләремә керә —
Тансык итәм сулар һавасын.
Сәхрәләргә чыгып бер урасаң,
Чәчкәләрдән илһам аласың.

Шәмдәлләрдә янган шәмнәр кебек,
Юкка гына йөрәк янмасын,
Язлар җиткәч кәккүкләрем кайтып,
Гомер озынлыгын санасын.

Ышанычым мине ташламады:
Кыш артында көткән язым бар.
Хәсрәт кулларennнән тартып алыр
Куанычы, яме, назы бар.

Афәтләргә бер дә юлыкмыйча,
Кайтсын иде кошлар иленә.
Тирәкләрем күптән сагынып көтә,
Моңсулыгы күзгә күренә.

Кош оясы агач башларында
Бала бишеге күк тирбәлә.
Дәртләндереп ташкан хисләр белән,
Җирдә моңнар, җырлар төрләнә.

Яшьлек ямен язлар алып килә —
Шанлы күкрәүләре күкрәсен.
Зәңгәр яз аеның гөреннәрен,
Ташуларын килә күрәсем.

Тирәкләрнең бөреләрен көтәм,
Куанычым сыймый күңелгә.
Дәрьяларым шашып ташыганда
Дөнья шау-шуларга күмелә.

Хәтеремә төшә узган язлар,
Үткәннәргә бага күзләрем.
Гомеремдә күргән югалтулар —
Үлчәвендә вакыт-бизмәннең.

Кошлар нәселеннән булмагачтын,
Төшкәләдем түбән тәгәрәп.
Кулны тотты тормыш мәшәкате,
Гел булмады дөньям түгәрәк.

Ачы күз яшем дә күп түгелде,
Горур баш та түбән иелде.
Бинахакка кеше газаплана —
Нинди каһәр төшкән бу илгә?

Халык зарын сизеп-белеп яшим,
Кайгы-хәсрәт ашкан башыннан.
Күпме генә гомер кичерелә —
Күренеп тора кабер ташыннан.

Бар күргәнем күңелемә күчеп,
Җырым булып туа дөньяга.
Йөрәкләрдән йөрәкләргә күчеп,
Җанны тетрәндергән моң ага.

Күпме язлар гомеремдә узды,
Өмет белән көтәм киләсен.
Еллар үткән саен язлар назлы,
Күркәм(е)рәк була, күрәсең.

Карлар, бозлар җирдә калмас әле,
Кояш кына көлсен — эрерләр.
Каршылаудан, озатудан гына
Торамы соң әллә гомерләр?..

II

Гомер сукмагыннан атлап киләм
Якты язга, яшел җәйләргә.
Яңа көнгә кергәч, сәлам бирәм
Аккан суга, искән җилләргә.

Учактагы утлар кебек дөрлим,
Казанында кайныйм — җәй җитсә.
Борчыламын, үкенәмен бары
Бер файдасыз әгәр көн үтсә.

Сәхрә-кырда узды озын көнем,
Сабан тотып үстем басуда.
Тузан йотып арып эштән кайттым,
Яшәгәндә күрдем барсын да.

Игенче дә, көтүче дә булдым,
Таш та ваттым, йорт та бурадым.
Горурлану, бер масаю белән,
Басулардан ничә урадым.

Җәй көнендә кулым бушап тормый,
Көрәк, сәнәк, чалгы тотамын.
Болыннарда, иген кырларында
Тургайларның җырын отамын.

Тирәкләрнең бөреләрен көтәм,
Куанычым сыймый күңелгә.
Дәрьяларым шашып ташыганда
Дөнья шау-шуларга күмелә.

Хәтеремә төшә узган язлар,
Үткәннәргә бага күзләрем.
Гомеремдә күргән югалтулар —
Үлчәвендә вакыт-бизмәннең.

Кошлар нәселеннән булмагачтын,
Төшкәләдем түбән тәгәрәп.
Кулны тотты тормыш мәшәкате,
Гел булмады дөньям түгәрәк.

Ачы күз яшем дә күп түгелде,
Горур баш та түбән иелде.
Бинахакка кеше газаплана —
Нинди каһәр төшкән бу илгә?

Халык зарын сизеп-белеп яшим,
Кайгы-хәсрәт ашкан башыннан.
Күпме genә гомер кичерелә —
Күренеп тора кабер ташыннан.

Бар күргәнем күңелемә күчеп,
Җырым булып туа дөньяга.
Йөрәклрдән йөрәкләргә күчеп,
Җанны тетрәндергән моң ага.

Күпме язлар гомеремдә узды,
Өмет белән көтәм киләсен.
Еллар үткән саен язлар назлы,
Күркәм(е)рәк була, күрәсең.

Карлар, бозлар җирдә калмас әле,
Кояш кына көлсен — эрерләр.
Каршылаудан, озатудан гына
Торамы соң әллә гомерләр?..

II

Гомер сукмагыннан атлап киләм
Якты язга, яшел җәйләргә.
Яңа көнгә кергәч, сәлам бирәм
Аккан суга, искән җилләргә.

Учактагы утлар кебек дөрлим,
Казанында кайныйм — җәй җитсә.
Борчыламын, үкенәмен бары
Бер файдасыз әгәр көн үтсә.

Сәхрә-кырда узды озын көнем,
Сабан тотып үстем басуда.
Тузан йотып арып эштән кайттым,
Яшәгәндә күрдем барсын да.

Игенче дә, көтүче дә булдым,
Таш та ваттым, йорт та бурадым.
Горурлану, бер масаю белән,
Басулардан ничә урадым.

Җәй көнендә кулым бушап тормый,
Көрәк, сәнәк, чалгы тотамын.
Болыннарда, иген кырларында
Тургайларның җырын отамын.

Җир хуҗасы итеп хис итәмен,
Тамырларым ята тирәндә.
Хезмәтемә көч тә, дәрт тә арта,
Иген басуларын күрәм дә.

Кызган таба кебек куырып ала,
Ашыктыра мине эшләрем.
Игенченең алы-ялы булмый,
Йокыларны бүлә төшләрем.

Ризык җыярга да вакыт тапмый,
Басу түрләрендә каламын.
Яңгыр ява башка, яшен яшьни,
Ихтыяр да, көч тә табамын.

Рәхмәтлемен үз шөгылем булгач,
Язмыш, мине җиргә бәйләдең.
Игеннәрем уңа, барын җыям,
Ямьле уза уңыш бәйрәмем.

Кайсы елны яңгыры да яумый,
Кайсы җәйдә коя чиләкләп.
Күтелмәгән чакта болыт килеп,
Бозлары да ява сирәкләп.

Еллар акрын гына уза тора,
Гомер сукмагымнан киләмен.
Әзме сулар акты, җилләр исте,
Яшәү рәвешенә күнәмен.

Дусларымны һаман югалтамын,
Җирдә арта кеше кабере.
Сирәк күрешәбез, үкендерә,
Бергә булган көннәр кадерле.

Моң-сагышка күңел тулышканда,
Серләремне кемнәр аңлар соң?
Болыт булып килә кайгылар да,
Читләп узмый адәм баласын.

Фани дөнья алдый кешеләрне —
Ике яшәми ич беркем дә;
Таулар чүгә, чишмә суы кибә,
Төрле хәлләр була бер көндә.

Учак уты кебек бар да сүнә,
Вакыт яңгырында юыла.
И, кояшым, күктә мәңгелексең,
Юлдаш бул син гомер юлыма.

Тормыш кочагында назла әле,
Золым-җәбереңне күрсәтмә.
Чуар заманага туры килдем,
Гаделсезлек, ачлык кисәтә.

Илләр күрдем, дөнья гизеп йөрдем,
Ни күрсәм дә килә яшисе:
Иҗат күгендә бер күкрисе,
Яшеннәре булып яшьнисе.

Йөрәк кенә түзсен, чыдар микән,
Йөз төрлегә көн дә төрләнәм.
Тәндә каным кызып ярсып таша —
Утлы ялкын җанга үрләгән.

Гомер сукмаклары алып килде —
Сары көзләремә керәмен.
Чана эзе кебек сызылып ята —
Йөзләремдә сырлар күрәмен.

Сары ялкын уртасында калдым,
Моңсу уйлар уела башыма.
Агач яфракларын җилләр түгә
Шыбыр-шыбыр урам ташына.

Яшьлек язым, бик еракта калдың,
Күзләрдән соң нәрсә күтәрмен?
Дөнья мәшәкате миннән калыр —
Мәңгелеккә бер көн китәрмен.

Кош юллары озын — күзәтәмен:
Кыр казлары, сез дә китәсәз.
Ялгыз кеше хәлен белмисез шул,
И ямансу, моңсу итәсез.

Таш кыялар сыман өнсез калсам,
Ишетәмен галәм авазын.
Коеп яуган күзнең яңгырлары
Юып алды яшьлегем назын.

Гармун күрегедәй сузып булмый —
Бик тә чикле кеше гомере.
Узган елларымның кайгысы да,
Үкенечләре дә кадерле.

Туып үскән җирем, рәхмәтлемен:
Суың эчтем, икмәк ашаттың.
Сабырлыгың, юмартлыгың өчен
Үз анама сине охшаттым.

Җир җылысын һәрчак тоеп яшим,
Юк, шиңмәде күңел гөлләрем.
Гомер кузым шәфәкъ нуры кебек,
Җитә ахры сүнәр көннәре.

Гомер сукмагында очрадылар:
Ятлар да бар, якын дуслар да,
Кара кайгылар да, шатлыклар да,
Күзем кызган асыл кошлар да.

Нидер җитми җирдә, кемнәрдер юк,
Иртәләрем нигә томанлы?
Мине чолгап алган билгесезлек
Диңгез төсле җәйрәп торамы?

Карлар күмәр, яңгыр суы юар
Сукмагымда калган эзләрне...
Өмет белән киләчәккә карыйм:
Еллар чакырып кулын изәде.

## АВТОР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Фәрит Суфияр улы Суфияров Яңавыл районының Исәнбай авылында туып үскән. Урта мәктәпне тәмамлагач, Уфа финанс техникумында белем ала. Төрле оешмаларда финансист-экономист булып эшли. Педагогия институтын тәмамлап, район гәзитендә әдәби хезмәткәр, мәктәптә директор вазифаларын башкара.

Озак еллар Башкортстанның төньяк-көнбатышындагы яшь һәм башлап язучыларны туплаган «Замандаш» әдәби берләшмәсен җитәкли. Хәзерге көндә — Яңавыл язучылар оешмасының җаваплы секретаре.

Шигырьләре вакытлы матбугатта, коллектив җыентыкларда дөнья күрә. Радио-телевидениедә аның сүзләренә язылган җырларны популяр җырчылар башкара.

Республикабыз әдәбиятын һәм сәнгатен үстерүдә күрсәткән хезмәтләре өчен шагыйрь Фәрит Суфияров Башкортстан Республикасының Мактау Грамотасына лаек булды, аңа «Башкортстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Ул — Гали Чокырый исемендәге премия лауреаты.

## ЭЧТӘЛЕК

Болын чәчәкләре. *Р. Тимершин* . . . . . . . . . . . . . 5

### *Шигырьләр*

Замандаш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Игенче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Җирем юмарт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Халкым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Җыр кирәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Буразналар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Таңнар елмая офыкта . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Икмәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
Туган ил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Кеше көтә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Авыл җанлана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Күзләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
Тәүге күкрәү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Тарту көче бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Эңгер төшкән мәл . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Йөрәгем кыңгыраулы . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Агын, күген күрдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Таулар иле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 22
Җир хөкеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Мин шикләнәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Борчуларым бетми . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Ай тотылган төндә . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Гомер йомгагы сүтелә . . . . . . . . . . . . . . . 26

Ялгыз каен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .27
Урманнарда йөрим . . . . . . . . . . . . . . . . . .27
Киләчәкне күзаллыйм . . . . . . . . . . . . . . . .28
Түзәрсеңме, йөрәк? . . . . . . . . . . . . . . . . . .29
Авылыма кайтсам . . . . . . . . . . . . . . . . . . .30
Мин көч табам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .31
«Дөнья хәзинәләр вәгъдә итә...» . . . . . . . . . .32
Яр башында куш каеннар . . . . . . . . . . . . . .32
Хезмәт бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .33
Кояш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .34
Минем өчен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .35
Хатирәләр яңартам . . . . . . . . . . . . . . . . . .36
Дүртьюллыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .36
Арышларым серкә очыра . . . . . . . . . . . . . . .40
Көнчелләр күп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .41
Ветераннар саны кими . . . . . . . . . . . . . . . .41
Өмет ялкыны сүнмәсен . . . . . . . . . . . . . . .42
Курешү көнен көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . .43
Зәңгәр кулмәгеңне ки . . . . . . . . . . . . . . . .44
«Эндәшмичә калам — көчем җитә...» . . . . . . .45
Дөньяга туа бала . . . . . . . . . . . . . . . . . . .45
Төрле вакыт мизгелләре . . . . . . . . . . . . . . .46
Апрель җиле исә . . . . . . . . . . . . . . . . . . .47
Кеше рәнҗемәсен . . . . . . . . . . . . . . . . . . .48
Рәхмәтеңне күрмим . . . . . . . . . . . . . . . . . .49
Халык ышана . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .50
Каберена чәчкәләр куям . . . . . . . . . . . . . . .50
Мин дә хушлашырмын . . . . . . . . . . . . . . . .51
Этләр өрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .52
Хатлар язам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .53
Өнсез калам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .54
Җир гаме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .55
Сиздермәскә телим . . . . . . . . . . . . . . . . . .55
Гармун тавышлары . . . . . . . . . . . . . . . . . .56
Гомер язлары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .57
Төнбоеклы күлем . . . . . . . . . . . . . . . . . . .58
Тугайларда җиләк җыйдым . . . . . . . . . . . . .59
Җир җылысын тоям . . . . . . . . . . . . . . . . . .59
Дәфтәремдә күңел ярсуларым . . . . . . . . . . . .60

Сукмакларда үлән үскән . . . . . . . . . . . . . . . . . . .61
Мин тугач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .62
Ташкент . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .62
Көтеп яшимен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .63
Бабам мирасы калган . . . . . . . . . . . . . . . . . . .64
Җанга тынгы бирми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .65
Утлар булып кабынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . .66
Миңа тансык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .66
Ир-егетләр чыга юлга . . . . . . . . . . . . . . . . . .67
Казлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .68
Вакыт җиткәч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .69
Ыжгыр бураннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .70
«Төрле хәлләр туып тора...» . . . . . . . . . . . . . .70
Табигать хөкеме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .71
Агымсу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .72
Күзләремдә калды нуры . . . . . . . . . . . . . . . . .73
Гөрләвекләр чыңлый . . . . . . . . . . . . . . . . . . .73
«Күл читендәге көймәләр...» . . . . . . . . . . . . . .74
Сусаган сәхрә-кырлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . .75
Тугайлар буйлап йөрдем . . . . . . . . . . . . . . . . .75
Хәтердә узган елларым . . . . . . . . . . . . . . . . . .76
Сиңа табындым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .77
Юлларыбыз очраштырмас . . . . . . . . . . . . . . . .77
Борчылма үткәнеңә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .78
Үз юлымнан киләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .79
Озатып калам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .79
Әнигә хат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .82
«Йорт сала күпләр бүген...» . . . . . . . . . . . . . .83
Гомер юлы төрле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .83
«Кышка керсәм, бар аклыгын аның...» . . . . . . .84
Мәңгелек моң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .85
Мин сөенәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .85
Безнең халык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .86
Каен үссен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .87
Дөнья яктысы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .88
Гомер бер генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .89
Туган җирең юксына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .89
Хаклык өчен җан атам . . . . . . . . . . . . . . . . . .90
Мин ышанам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .91

Кулымда була китап . . . . . . . . . . . . . . . . . . .91
«Хөрмәт итәм — данга лаек була...» . . . . . . . . . .92
Авыр хәлгә калгансың . . . . . . . . . . . . . . . . . . .93
Хатыннар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .94
Олы юлга чыгам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .94
«Без дә казлар саклап үстек...» . . . . . . . . . . . . .95
Поездларны юлга озатам . . . . . . . . . . . . . . . . . .96
Хәтер капчыгым тулы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .97
Күңел кошларым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .98
Курку белмәдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .98
Җанны өшеттең . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .99
Авыл урамнары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .100
Күкри яшьлек җырыбыз . . . . . . . . . . . . . . . . . .101
Үз җиремдә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .101
Җирдә яшәр хакым бар . . . . . . . . . . . . . . . . . . .102
Мәкерле кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .103
Гармуным кулларымда . . . . . . . . . . . . . . . . . . .104
Очрашкан юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .104
Төннәр буе чигү чигәсең . . . . . . . . . . . . . . . . .105
Кеше . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .105
Сабан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .106
Солдат кайтты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .107
Язгы җил . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .107
Сандугачкай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .108
Күрешү көнен көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .109
«Гашыйк итте мине бер кыз...» . . . . . . . . . . . . .110
Малай чаклар кайда калды? . . . . . . . . . . . . . . .110
Соңлап килә язлар да . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .111
Җырланмаган әле җырларым . . . . . . . . . . . . . . .112

*Җырлар*

Бала чагым чишмәләре . . . . . . . . . . . . . . . . . .114
Язлар көтәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .115
Серләремне кемгә сөйлим . . . . . . . . . . . . . . . .115
Бәхетле бул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .116
Сине юксынам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117
Беж сулары . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .117
Сине уйлыйм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .118

Туган як моңы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .119
Чик куйдың сагышыма . . . . . . . . . . . . . . . .120
Яшәсәк икән бергә . . . . . . . . . . . . . . . . . . .120
Талпынам, канат кагам . . . . . . . . . . . . . . .121
Яшьлегем кайтавазы . . . . . . . . . . . . . . . . .122
Хан чишмә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .123
Карашыңны сагынам . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Күз нурларың . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .124
Гафу ит син, мәхәббәтем . . . . . . . . . . . . .125
Йөгереп каршы чыгам . . . . . . . . . . . . . . . .126
Бүә буйларына килмисең . . . . . . . . . . . . .126
Сиңа әйтер сүзләрем бар . . . . . . . . . . . . .127
Бирешмә кайгыларга . . . . . . . . . . . . . . . . .128
Туган җирем, бергенәм . . . . . . . . . . . . . . .129
Дулкыннар ярга кага . . . . . . . . . . . . . . . . .129

***Поэмалар***

Көн каршына киләм . . . . . . . . . . . . . . . . . .132
Авылым кешеләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . .148
Гомер сукмагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .159

*Автор турында белешмә* . . . . . . . . . . . . . .170

Литературно-художественное издание

СУФИЯРОВ Фарит Суфиярович

ВЕСНЫ ЖИЗНИ

Стихи, поэмы, песни

*(на татарском языке)*

Редакция мөдире *Сабир Шәрипов*
Мөхәррире *Динә Морзакаева*
Рәссамы *Искәндәр Нигъмәтҗанов*
Бизәүче мөхәррир *Азат Мөхтәруллин*
Техник мөхәррире *Зәйтүнә Чингизова*
Корректоры *Гөлшат Абдуллина*

Нәшр. лиц. № 04380; 26.03.01. Җыярга бирелде 11.02.02. Басарга кул куелды 11.04.02. Форматы $70\times90^1/_{32}$. Офсет кәгазе. Мәктәп гарнитурасы. Офсет ысулы белән басылды. Шартлы басма таб. 6,43. Шартлы буяу отт. 6,72. Исәп-нәшер таб. 6,19. Тиражы 1000 данә. Заказ № 676.

Башкортстан «Китап» нәшрияты дәүләт унитар предприятиесе,
450001, Уфа, Левченко урамы, 4а.

Әзерләп бирелгән диапозитивлардан басылды.
Уфа полиграфия комбинаты дәүләт унитар предприятиесе,
450001, Уфа, Октябрь проспекты, 2.

